ПРЕЗИДЕНТ ӘЙТТЕ

Владимир Путин Федераль Җыенга Юлламасында нинди мәсьәләләргә игътибар итте?

> 2

ВАТАН ХАКЫНА

Батырлык, патриотизм сүзләренең асыл мәгънәсенә төшенергә тырышып яшәгән көннәребез

> 6–7

ӘНВӘР НУРГАЛИЕВ:

«Миңа җиңелчә генә тәртипсезлек тә гафу ителми».

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 27 (28994) | Чәршәмбе | 22 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАДЕРЛЕ БАТЫРЛАР

МУСА ҖӘЛИЛ БӘЙГЕСЕНДӘ ЛАЕШ ЕГЕТЛӘРЕ ҖИҢДЕ

Газетабыз гамәлгә куйган көрәш турнирында бу район командасы тәүге җиңүен яулады. Шәхси ярышта исә 7 егет узган елгы батырлыгын кабатлый алды. Быел 60 нчысы узган юбилей бәйгесендә көрәш ветераннарын зурладык, бүгенге батырларга сокландык, милли спорт төренең киләчәге турында уйландык.

> 16–17

Ишетми калмагыз

Татарстанда бер ел эчендә – 2022 елның гыйнварыннан быелгы гыйнвар аена кадәрге чорда – хезмәт хакы уртача 7969 сумга арткан. Әмма барыбер Россия күләмендәге уртача күрсәткечкә җитмәгән.
HeadHunter сервисы белгечләре исәпләп чыгарганча, республикада 2023 елның гыйнвар аенда айлык эш хакы күләме уртача 53958 сум тәшкил иткән. Шул ук вакытта Россия буенча әлеге күрсәткеч уртача 58179 сум булган.
Идел буе федераль округына килсәк, хезмәт хакы уртача 7234 сумга үскән. 2022 елның гыйнварында 44748 сум булса, 2023 елның гыйнварында – 51982 сум.

Республикада быел гыйнвар аенда инфляция күрсәткече Россия һәм Идел буе федераль округындагыдан кимрәк дәрәҗәдә – 11,55% булган. Үзәк банкның республикадагы бүлеге матбугат хезмәте хәбәренә караганда, федераль округта шушы чорда инфляция 11,71% тәшкил иткән. Россия буенча – 11,77%.
Россия банкы белгечләре фаразы буенча, илебездә берничә ай дәвамында инфляция күләме вакытлыча 4 процентган түбәнрәк булачак. Шул ук вакытта икенче яртыеллыкта әлеге күрсәткеч берникадәр артырга мөмкин. Шулай итеп, еллык инфляциянең 2023 елда – 5,0–7,0% булып, 2024 елда – элеккеге 4 процентка кире кайтуы һәм алга таба да шул чама тәшкил итүе көтелә.

Узган елда Татарстанда мал-туар, сукбай хайваннардан зыян күргән 9,6 мең кеше табибларга мөрәҗәгать иткән. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, 100 мең кешегә 258,97 шундый очрак туры килгән. Бу – алдагы ел күрсәткеченнән 5,98 процентка кимрәк. Күңелсез очракларның яртысы хуҗасыз хайваннардан зыян күрүгә туры килә.

Татарстанда мошенникларны тотканнар. Алар, туганыгыз бәлагә юлыккан, аны коткару өчен фәлән сум акча кирәк, дигән булып, телефон аша өлкәннәрне алдаган. Якын чит илдән килгән 3 ир-ат 2021 елның августыннан бирле 11 шундый җинаять кылган. Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәренә караганда, алар пенсионерларның барлыгы 2,7 миллион сум акчасын урлаган. Җинаятьчеләрне эзләү бүлеге хезмәткәрләре иң элек өлкәннәрнең акчасын алырга килүченең эзенә төшкән. Аны Казан аэропортында Волгоградка очар алдыннан тоткарлаганнар. Калган ике ир-ат Мәскәүдә тотылган. Хәзерге вакытта алар барысы да – сак астында.

ВЛАДИМИР ПУТИН: «ДӨРЕСЛЕК БЕЗНЕҢ ЯКТА!»

1 сәгать тә 45 минут. Россия Президенты Владимир Путинның Федераль Җыенга Юлламасы әнә шулкадәр дәвам итте. Илбашына дүрт тапкыр аягүрә басып кул чаптылар. Махсус хәрби операция, ил икътисады, гаиләләргә ярдәм чаралары һәм бердәмлек турындагы Юлламаны «ВТ» хәбәрчесе дә тыңлады.

Махсус хәрби операция турында

Украинада махсус хәрби операция башланганнан бирле, бу – Илбашының парламентка тәүге мөрәҗәгате. Соңгы тапкыр Владимир Путин Федераль Җыен алдында 2021 елның апрелендә чыгыш ясады. Шуңа күрә алдан ук быел Юлламада махсус хәрби операция темасы кызыл җеп булып узачак дип фаразладылар. Шулай булды да.

– Моннан бер ел элек тарихи җирләребездә яшәүче халкыбызны яклау, илнең иминлеген тәэмин итү, 2014 елгы кискен борылыштан соң Украинадагы неонацистлар режимыннан янаган куркынычны юкка чыгару өчен махсус хәрби операция башлау турында карар кабул ителде, – диде Илбашы. – Без адымлап һәм эзлекле рәвештә алда торган мәсьәләләрне хәл итәчәкбез. Донбасс 2014 елдан бирле үз җирендә яшәү хокукы өчен көрәште һәм Россия ярдәмгә киләчәгенә ышанып яшәде. Үзегез күреп торасыз, без ничек тә мәсьәләне тыныч юл белән хәл итәргә тырыштык. Килешүләр алып бардык. Тик безнең артта, гомумән дә, икенче план корып ятканнар. Махсус рәвештә вакыт сузганнар. Тагын бер кат кабатлыйм: сугышны алар башлады, без исә көчне әнә шул сугышны туктату өчен кулланабыз. Үз халкыбызны, туган йортыбызны саклыйбыз.

Саннардан да чәчләр үрә торырлык. Аларны Илбашы китерде. Халыкара икътисадый хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасы мәгълүматларына караганда, Бөекбритания, Германия, Италия, Канада, Франция, Япония һәм АКШны берләштерүче «Зур җиделек» бу сугышка 150 миллиард доллар акча бүлеп биргән инде. Шул ук вакытта, 2021–2022 елларда фәкыйрь илләргә 60 миллиард долларлык акчалата ярдәм күрсәткән.

– Бу без уйлап чыгарган саннар түгел. 2001 елдан бирле АКШ башлап җибәргән сугышларда 900 меңнән артык кеше үлгән, 38 миллионнан артык кеше качакка әйләнгән. Хәзер исә берни дә булмаган кыяфәт чыгаралар. Юк, беркем дә онытылмаган, бер нәрсә дә онытылмаган! – диде Илбашы.

Алдан китеп булса да әйтик, Владимир Путинның чыгышы шигарь булырлык җөмләләргә бай иде. Шуңа күрәме, аны даими рәвештә алкышларга күмеп тордылар. Дүрт тапкыр аягүрә басып кына кул чаптылар.

Без Украина халкына каршы көрәшмибез, дип тә каткат искәртте Владимир Путин. Ул аларның үзләрен дә Көнбатыш кулындагы «корбан»нар дип бәяләде. Аның әйтүенчә, Украина – Россиягә каршы көрәштә калкан, сугыш мәйданы гына. Максатлары билгеле – Россияне юкка чыгару. Моның чынга ашмаслык хәл икәнен дә әйтте Илбашы. Аның сүзләренә караганда, каршы як Украинаны көчлерәк корал белән тәэмин иткән саен, ил хәрбиләре дә эчкәрәк керергә мәҗбүр булачак.

– Күпмилләтле Россия халкының зур күпчелеге махсус хәрби операциянең мәгънәсен, аның ни өчен кирәк булуын аңлады, безгә теләктәшлек белдерде. Мин сезнең белән горурланам, – диде ул.

Ватан сакчыларына ярдәм турында

Бүгенге шартларда иң кыен хәлдә калган гаиләләр – махсус хәрби операциядә туганнарын һәм якыннарын югалтучыларны, ветераннарны ярдәмнән ташламаска да вәгъдә итте. Моның өчен быел ук ил күләмендә махсус дәүләт фонды оешачак. Эштә «кәгазь боткасы» ясап ятмаска кушты Илбашы. Президент әйтүенчә, дәвалану, укуны дәвам иттерү, матди ярдәм күрсәтү кебек мәсьәләләрне хәл итү өчен һәр гаиләгә аерым координатор билгеләнәчәк. Ә махсус хәрби операциядә катнашучыларга ким дигәндә ярты елга бер тапкыр, юлга киткән вакытны исәпкә алмыйча, 14 көнлек ял бирәчәкләр. Өйләренә кайтып, туганнарын күреп килсеннәр. Илбашы яңа торак программасы турында да әйтте. Ул оборона-сәнәгать комплексы тармагында эшләүчеләргә кагылачак, ди.

kremlin.ru

Икътисад турында

Владимир Путин әйтүенчә, ил икътисады Көнбатыш илләре санкцияләре басымына каршы тора алуын күрсәтте. «Чикләүләр кертүче илләрнең өметләре акланмады. Санкцияләр үзләренә үк тискәре яктан тәэсир итте. Без эш урыннарын саклап калдык, дефицитны булдырмадык, эшкуарларга триллион сум күләмендә ярдәм күрсәттек. Ил икътисады 25 процентка кадәр төшә утырачак дип фаразласалар да, әчке тулай продукт нибары 2 процентка гына кимеде. Икътисадый күрсәткечләр үсте», – диде ул.

Алдагы эш тә җитәрлек. Аерым алганда, безгә дустанә мөнәсәбәттә булган илләр белән логистиканы җайлаячаклар. «Мәскәү – Казан» югары тизлекле юлын Екатеринбургка, аннан Чиләбе һәм Төмәнгә, ә тора-бара Казахстанга, Монголиягә һәм Кытайга кадәр салу күздә тотыла, дигән фикер әйтте Илбашы.

Акча турында сөйләгәндә, Владимир Путин махсус хәрби операция башлангач, чит илдә туплаган байлык артыннан илдән чыгып качучыларны да искә төшерде.

– Россияне акча эшләү өчен генә файдаланып ятучылар оттырды, – диде ул. – Аларны чит илдә таладылар әнә. Ышаныгыз: илдә яшәүче гади халык чит илдәге сарайларыннан, яхталарыннан колак кагучыларны тамчы да кызганмады.

Илбашы бу хакта сөйләгәндә залда утыручыларның елмаюлы йөзләрен дә күрсәтеп алдылар. Президент исә фикерен дәвам итеп, теләге булганнарга чит илдә «олтан» булып яшәгәнче, кире үз Ватанына кайтып, илгә ярдәм итү мөмкинлеге турында искә төшерде.

Киләчәк турында

Тагын бер яхшы яңалык: киләсе елдан хезмәт өчен түләүнең минималь күләме 18,5 процентка артып, 19 мең 242 сумга җитәчәк. Илнең яңа төбәкләрендә ана капиталы гамәлгә керәчәк. Аны 2007 елдан соң туган бөтен балаларга түләргә тәкъдим иттеләр. Бала тәрбияләүче гаиләләргә салым түләүдә ташламаларны арттыру да күздә тотыла. Билгеле булганча, узган елдан ике һәм аннан да күбрәк бала үстерүче гаиләләр тагын да зуррак торак сатып алган очракта, салым түләүдән азат ителә.

Илнең мәгариф тармагын да зур үзгәрешләр көтә. Алдагы биш елда миллионлаган эшче һөнәр ияләре әзерләү бурычын куйды Илбашы. Ә югары белем бирүнең элеккеге традицион системасын кайтарачаклар. Президент шулай диде. Уку вакыты 4–6 елга калачак. Тар белгечлекләр буенча магистратурада яки ординатурада белем алуны дәвам итәргә мөмкин булачак. Аспирантурада исә фән һәм укыту эшчәнлеге буенча белгечләр әзерләячәкләр. Яңа системага күчү өчен мәгариф һәм хезмәт базарына кагылышлы законнарга күп төзәтмәләр кертергә кирәк булачак, дип тә искәртте Илбашы. Шул ук вакытта, бу – хәзерге программалар буенча белем алучыларга яки элегрәк диплом алучыларга кагылмаячак.

Көнүзәк мәсьәләгә әйләнеп кайтып, Владимир Путин СНВ-3, стратегик һөҗүм итү корраллары турындагы килешүдә (Россия белән АКШ арасында 2010 елдан бирле гамәлдә. – **Ред.**) катнашуны туктатып тору турында белдерде.

– Без әлеге килешүдән чыкмыйбыз, бары тик әлеге эшне туктатып кына торабыз, – диде Илбашы. – АКШ атом-төш коралын сыный башласа, без дә җавап бирәчәкбез. Махсус хәрби операциядә төрле милләт һәм дин вәкилләре бердәм булып катнаша, аларның догалары төрле телләрдә яңгырый. Без – бер ил, бердәм халык. Дөреслек безнең якта!

Әлеге сүзләр яңгыраганда залда утыручылар торып баскан иде инде.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Зилә ВӘЛИЕВА, Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе:
– Президент Юлламада махсус хәрби операция турында күп мәгълүмат бирде. Бу теманың мөһимлеген аңлап, хәрбиләребезне кайгырту турында да әйтте. Аларның гаиләләрен аерым игътибарга алу турында да сүз булды. Президент моны кат-кат әйтте. Бу эштә бюрократия булмаска тиеш, диде. Ул моны Президент кына түгел, иң элек кеше буларак әйтте.
Махсус операция зонасыннан килеп торган хәбәрләрне һәркем акылы белән дә, йөрәге белән дә кабул итә. Борчылу һәммәбездә бар. Президент Путин халыкның бердәм булуына да басым ясады һәм һәркемнең җиңүгә үз өлешен кертергә тырышуын әйтте. Мин аның фикере белән тулысынча килешәм. Бу эштә аз һәм күп дигән сүз була алмый. Зур эшмәкәрләр ярдәм күрсәтәме, әллә пенсиясеннән өлеш чыгаручы апа-абыйлармы, ихлас хатлар язган мәктәп балаларымы – безнең халык чынлап та ярдәмчел ул. Кайда гына, нинди генә фондлар ачылмасын, ул фондлар булышырга теләк белдерүчеләр белән шул ук көнне тула. Кем ничек булдыра, шулай булыша. Ул ярдәмне үлчәүгә салып булмый. Юлламада Президентның җәмгыятькә рәхмәте дә яңгырады. Бу һәр оешмага, һәр кешегә әйтелгән рәхмәт.

Сәрия САБУРСКАЯ, Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:
– Президент, иң беренче чиратта, илебезнең көче, аның чикләрен саклаучы кешеләр, Украинада барган вакыйгаларда якыннарын югалтучыларга мөнәсәбәт турында сөйләде. Бу бик мөһим. Егетләребезнең махсус хәрби операциядә никадәр күп көч, егәр куеп көрәшүен күреп торабыз. Президент Юлламасында алар белән чиксез горурлану чагыла иде. Владимир Путин бүген яу кырында көрәшкән каһарман егетләребез, гуманитар ярдәм җыю, хәйриячелек кебек изге гамәлләр аша аларга ярдәм итеп торучылар турында бик җылы итеп сөйләде. Алардан килгән бер генә мөрәҗәгатьнең дә игътибардан читтә калмаска тиешлеген искәртте ул. Оборона министрлыгына бу уңайдан җитди күрсәтмә бирде. Владимир Путин социаль ярдәм чараларына да аерым тукталды. Бигрәк тә гаиләләргә, балаларга, яшьләргә ярдәм итәргә кирәклеген искәртте ул. Президентның Юлламада әйткән сүзләре бик зур хөрмәт һәм иң мөһиме – иртәгесе көнгә ышаныч уята.

Тимур СӨЛӘЙМАНОВ, Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Беренчеләр хәрәкәте» бөтенроссия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең республикадагы бүлеге җитәкчесе:
– Президент Юлламасында яшьләргә, бигрәк тә көллияттә, вузда укучы студентларга зур игътибар бирелде. Тезисларның күпчелеге яшьләрне тәрбияләү, алар өчен мохит булдыру турында, традицион кыйммәтләргә бәйле иде. Ул бүген безнең республикада алып барылган сәясәткә бик тә туры килә. Татарстанда яңа хәрәкәт булдырылды. Без хәзерге вакытта мәктәпләрдә, көллиятләрдә, яшүсмерләр клубларында шул хәрәкәтне җәелдерә башладык. Яшьләрнең, укытучы, директорларның, ата-аналарның шул инициативага мөнәсәбәте куандыра. Бу хакта шундый зур трибунадан – илебез лидерыннан ишетү, миңа калса, тәрбия эше белән шөгыльләнгән кешеләргә өстәмә көч, дәрт бирә.

ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ БЕЛӘН!

tatarstan.ru

23 февральдә Россия Федерациясе Кораллы Көчләре үзләренең төп бәйрәмен – Ватанны саклаучылар көнен билгеләп үтә.

Ватаныбыз хакына хезмәт иткәннәргә, хәзер хезмәт итүчеләргә яки Россия армиясе һәм флоты сафларына әле кушылырга гына әзерләнүчеләргә, шулай ук тыныч тормыштагы хезмәте, хәрби батырлыгы белән дәүләтебезнең иминлеген, тотрыклылыгын булдыруга, бөек Ватаныбызның көч-куәтен, данын арттыруга өлеш кертүчеләрнең һәммәсенә карата зур ихтирам хисләре белән сугарылган бәйрәм бу.

Иң элек авыр сугыш елларында үзләренең ватанпәрвәрлек бурычын намус белән үтәгән Бөек Ватан сугышы ветераннарын котлыйсы килә. Бүген аларның данлыклы каһарманлык традицияләрен махсус хәрби операция зонасында хәрби бурычларын башкаручылар, батырлык һәм геройлык үрнәкләрен күрсәтеп, ышанычлы төстә дәвам итә.

Татарстан Республикасы да илнең оборона куәтен ныгытуга үзеннән саллы өлеш кертә. Илебезнең хәрби-сәнәгать комплексына керүче Татарстан предприятиеләренең зур көч-куәткә ия булуы, армия һәм флотны заманча корал һәм техника белән тәэмин итеп, иң катлаулы оборона заказларын үтәү мөмкинлеге бирә.

Бу бәйрәм көнендә барлык хәрби хезмәткәрләргә, хатыннары, әти-әниләре, балаларына һәм, гомумән, Татарстанда яшәүче барча кешегә нык сәламәтлек, уңышлар, оптимизм рухы һәм иртәгесе көнгә ышаныч телим.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
Алексей ПЕСОШИН

СӨЙЛӘШСӘК ТӘ ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ...

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Милли бәйрәмнәрнең мәгънәсен күрсәтү, дастаннарны өйрәнү, халыклар бердәмлеген ныгыту. Татарстан Хөкүмәте йортында узган брифингта республикада игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының ничек узачагы турында сөйләделәр. Бу уңайдан республикада 350гә якын чара оештырырга җыеналар.

Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова сүзен Халыкара туган тел көне белән котлаудан башлады.

– Тел – мәдәниятебез, мирасыбыз белән таныштыруда төп корал. Без моны яхшы аңлыйбыз. 2023 елның республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителүе сөендерә. Быел да, башка елларда да безнең төп бурыч – һәр халыкның гореф-гадәтен, милли үзенчәлеген саклау, үстерү һәм популярлаштыруга ярдәм итү. Без моңа уртак тырышлык белән генә ирешә алабыз, – диде ул.

Ирада Әюпова сүзләренчә, мәдәни сәясәтнең төп бурычларыннан берсе – республикада яшәүче халыкның мәдәни һәм тел мирасын саклап калу, балаларда һәм яшүсмерләрдә милли үзаңны үстерү, аларда милләтара мөнәсәбәтләр культурасын тәрбияләү.

Республикада Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елын уздыру буенча төп чараларны мәгариф, фән, мәдәният, инфраструктураны үстерү, матди-техник җиһазлау юнәлешләре буенча тормышка ашыралачаклар.

Республикада яшәүче халыкларның бердәмлеген ныгыту максатыннан исә, 1 марттан 30 декабрьгә кадәр узачак «Татарстанның чигелгән картасы» республика акциясе оештырылачак. Ирада Әюпова сүзләренә караганда, әлеге акция декоратив-гамәли сәнгать аша халыкларның уникаль традицияләрен күрсәтәчәк.

– Бүген без җирле традицияләрне саклауга зур игътибар бирәбез. Чөнки конкрет территорияләрнең традицияләрен саклап, без мәдәниятебезне саклыйбыз. Ә мәдәният күбрәк авылларда саклана. Шуңа күрә быел авылларда бик күп чаралар оештырырга ниятлибез. Һәрберебез

«Татар-информ»

күпмилләтле республикабыз халыкларының мәдәни-милли үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре белән танышып дип уйлыйм, – диде мәдәният министры.

Милли традицияләр турында сөйләшкәндә, милли бәйрәмнәр турында да сүз кузгатмыйча булмый. Мәдәният министры быел традицион бәйрәмнәрне уздыру буенча эш алып барылачагын әйтте.

– Ел саен республикабызда яшәүче халыкларның традицион бәйрәмнәре уза. Быел без аларны яңартачакбыз. Бу барлык бәйрәмнәргә дә кагыла. Сабантуй да, Уяв та, Питрау да, Семык та, җыеп әйткәндә, һәр бәйрәм, һәр йоланың үз нигезе, үз традицияләре бар. Вакыт узу белән аларның үзгәрүе – табигый күренеш. Тик ул үзгәрешләр чараның мәгънәсен юкка чыгарырга тиеш түгел. Киресенчә, без быел милли бәйрәмнәребезнең мәгънәсен күбрәк күрсәтергә тырышачакбыз, – диде министр.

Татарстан халыклары ассамблеясы советы рәисе урынбасары Константин Яковлев фикеренчә, милли традицияләр һәм бәйрәмнәр иң элек телне, мәдәниятне саклаудан башлана:

– Татарстан – барыбыз өчен уртак йорт. Республикабыз күпмилләтле һәм без, үзара аңлашып, мәдәни традицияләрне саклап кала алабыз. Бу җәһәттән халык та активлашты. Нәсел тамырлары белән кызыксынучылар бермә-бер артты. Бүген бу бигрәк тә мөһим.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров ел дәвамында уздырылачак чараларны милли дастаннарга бәйләп оештыру турында әйтте.

– Татар дөньясы Татарстан белән генә чикләнми. Без уздыра торган чаралар һәм без алып барган эш юнәлешләре республикадан читтә булган татар оешмаларына да кагыла. Аларның барысының да карашлары Татарстанга, Казанга төбәлгән, – диде Данис Шакиров. – Узган елны Татарстан Рәисе Дәүләт Советына Юлламасында халык шагыйре Мөдәррис Әгъләмнең ярты гасыр элек язылган шигырь юллары белән башлап җибәргән иде. Туган тел һәм туган җир – игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елының кызыл җеп булып баручы ике төшенчәсе. Шуның кысасында без Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасында 2023 елны Милли дастаннар елы дип игълан иттек. Еш кына дастаннарны филология күзлегеннән һәм эпик әсәр төре буларак кына беләбез. Ләкин аны тарихи чынбарлыкны чагылдырган милли горурлык чыганагы буларак кабул итәргә кирәк. Дастаннарны өйрәнү балаларда һәм киң җәмәгатьчелектә милли үзаң тәрбияләүнең төп ысулы булып тора.

Милли бәйрәмнәрсез дә булмый, билгеле. Данис Шакиров быел илнең 59 төбәгендә, 37 чит илдә 388 Сабан туе уздыру планлаштырылуы турында әйтте. Аның сүзләренчә, дөньяда нинди генә вазгыять булса да, татар оешмалары милли бәйрәмне оештырачак.

Ләйсән САФИНА

Районнарда ни хәлләр?

Мамадыш

Тәкәнеш авылында яшәүче Өммениса Һадиевага 20 февральдә 107 яшь тулды. Моннан өч ел элек туган көн иясе кунакларны үзе каршы алып, сыйлап җибәрә торган булган. Аягы авыртканга күрә, бу юлы ул котлауларны утырган җиреннән генә кабул итте. Өммениса әбине гомер бәйрәме белән котларга район башлыгы Анатолий Иванов һәм Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге башлыгы Рөстәм Хәмизуллин да килде. Узган гасырның 20 нче елларындагы коточкыч ачлыкны, Бөек Ватан сугышын кичергән Өммениса әби, беркайчан да дару эчмәдем, ди. Күбрәк хәрәкәтләнергә тырышкан, суны бары тик чишмәдән генә эчкән. Шулай да, озак яшәвенең төп сере дип, кешеләргә яхшы мөгамәләдә булуны атый ул. Яшәү дәверендә бәла-казаларны шактый кичерсә дә, тормышны ярата акъәби.
(«Нократ»)

Актаныш

«Актаныш-информ» бу көннәрдә тулысынча яңарыш кичерде. Радио бүлеге туры эфирда эшли башлады. Бу яңалыкны тормышка ашыру өчен, заманча аппаратура, башка мөмкинлекләре дә бар хәзер, аларның барысы да Татарстан Хөкүмәте, «Татмедиа» җитәкчелеге ярдәме белән булдырылды. «Эфирга шалтыратучыларның һәрберсе безне шушы яңалык уңаеннан котлады, эшебездә уңышлар теләде. Моннан 10 ел элек Актаныш радиосында туры эфирлар тукталып калган иде. Бүген мин үземне яшьлегемә кайткан кебек хис иттем. Тыңлаучылар белән рәхәтләнеп аралаштым. Безне Актаныштa гына түгел, күрше Башкортстанда да яратып тыңлыйлар. Бүген күп сәламнәр Яркәй, Илеш якларыннан килде», – ди туры элемтәгә беренчеләрдән булып чыккан радиохәбәрче Фәния Рәшитова.
(«Актаныш-информ»)

Буа

Район үзәгендә «Приют человека» проекты кысасында мохтаҗларны кайнар аш белән тукландыру урыны ачылды. Биредә көн саен 50 өлеш азык әзерләү планлаштырыла. Соңрак, ихтыяҗга карап, бу сан артачак, ди оештыручылар. Шәһәрдә мондый урын ачу идеясен шушы районнан чыккан хәйрияче Ильяс Гыймадов биргән. Буа районы башлыгы Ранис Камәртдинов сүзләренчә, «Приют человека» – район өчен мөһим проект. «Башкаларга ярдәм итеп, без тагын да камилләшә алабыз», – ди ул.
(«Байрак»)

Алабуга

Районның биш мәктәбендәге ашханәләрдә капиталь ремонт булачак. Төзекләндерү эшләренә 23 млн сум тирәсе акча тотарга җыеналар. Шәһәрнең 4 номерлы гимназиясе һәм 11 номерлы мәктәбендә, шулай ук Морты, Олы Шүрнәк һәм Иске Юраш авылы мәктәпләренең ашханәләрендәге ремонт эшләре балаларның җәйге каникулы вакытында башкарылачак. Аларда идәннәр, диварлар һәм түшәмнәр яңартылып, пешерү зонасына яңа җиһазлар урнаштырылачак.
(kazanfirst.ru)

Әйтеп кенә бактым

Талант

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бер дустым белән сүзгә килеп алдык әле. Бөтенләй үк бозылышмадык үзе, әмма шактый кыза-кыза бәхәсләштек. Мин: «Иҗат кешесенә Ходай биргән талант кирәк», – дим. Ә ул: «Ходай беркемне дә аерып тормый, талантны-сәләтне һәркемгә тигез итеп бүлеп бирә», – ди. Моңа ышанасы килми. «Мәсәлән, теләсә кем шагыйрь, йә композитор була алмый бит инде», – дип карыйм. Ә дустымның үз туксаны – туксан: «Була ала. Әмма кеше үзендә ниндидер талат барын белмәскә мөмкин. Белмәгәч-сизмәгәч, ул аны үстерә дә алмый, үзе белән теге дөньяга да алып китәргә мөмкин», – ди.

Талантның геннар буенча килүе турында да сөйлиләр. Мин атаклы кешеләрнең нәсел-нәсәбе белән кызыксынган идем. Мәктәптән үк һәркемгә таныш булган Коперник, Ньютон, Паскаль, Вольт, Фарадей кебек акыл ияләренең нәселендә, мәсәлән, танылган шәхесләр тапмадым.

Әле бит, талантлы кешеләрдән талантлы балалар туа, дигән фикер дә яши. Бу фикерне куәтләүчеләр композитор Бахны телгә алалар. Аның нәселендә 26 музыкант булган икән.

Безнең татар ай акыллы, ай талантлы да инде: берәр нәрсә шып иттеме – йә җыр, йә шигырь, йә бәет чыгара. Аның яшәешебездәге һәр күренешкә әйтемнәре дә бар. Әйтемнәрне әйтәм әле, алар еллар буе сөйләнеп, үзенә күрә бер хакыйкатькә әйләнеп бетсәләр дә, мәгънәләре белән ни өчендер бер-берсенә каршы да киләләр. Мәсәлән, «Алма үз агачыннан ерак төшми» дигәне белән янәшә «Аттан ала да туа, кола да туа» дигәне дә яшәп килә.

Хәер, мондый мәгънәви каршылык урыс кардәш телендә дә бар. «Мәсәлән, «Талант не пропьешь» дигәненә җавап итеп дигәндәй, алар авыз тутырып: «Все мозги пропил», – дип әйтәләр. Бу образлы сөйләмне без татарчага да әйләндереп өлгердек һәм шулай ук авыз тутырып: «Мозгасын эчеп бетергән», – дибез.

«Рус белән сайрашып» гомер кичерү шул дәрәҗәгә җитте ки, без инде урысча кыстырмыйча сөйләшә дә алмый башладык. Бу, бер уйлаганда, татарның талантлы икәнен дә күрсәтә. Чөнки чит телләр өйрәнү өчен дә аерым талант кирәк, диләр бит. Классикларның кайсы икәнен хәтерләмим, әллә Маркс, әллә Энгельс инде, гарәп телен өйрәнүне әллә ничә башлап, әллә ничә ташлаганнар. Нинди акыллы кешеләр, ә тел өйрәнергә талантлары җитмәгән. Ә без – талантлы халык, безгә русчага өйрәнү, мәсәлән, берни тормый. Башлап-ташлап торасы юк, «мозга»бызга үзеннән-үзе керә.

Шуны уйлап куйдым әле: талант, сәләт кенә түгел, ана теле дә Ходай бүләге бит. Әйтүләренчә, ана теле бала күңеленә анисе карынында чакта ук инделәә. Алай гына да түгел, бәндә баласы әле яралгы хәлендә үк дөньяны аз-маз таный башлый, аның характеры да формалаша, имеш. Әмма, якты дөньяга аваз салып, аерым бер шартларда яши башлагач, кеше бишектәге бала кебек бишкә төрләнә. Чолгап алган тирәлек, мохит үзенекен итеп, Ходай биргән бүләкләр, шул җөмләдән тел турында да оныта башлыйбыз. Ул хәтле үк Алласыз булмаска иде инде, кардәшләр.

БУЛМАГАННЫ КЕМ ЯСАР?

Дөньякүләм көндәшлек дәүләтләрне матди проблемаларны чишүнең яңа ысулларын эзләүгә этәрә. Беркемнең дә икътисадый коллапс җимерекләре астында каласы килми, һәркем өскә калкып чыгарга омтыла.

vk.com

Кытайны бөтендөнья фабрикасы итәбез дип хыялланучылар оттыруларын аңлый башлады: чиннар бүген икътисадый яктан нык үскән илләрнең барысы бергә кулланган кадәр электр энергиясе куллана. Чин сәнәгатенең кискен ыргылыш ясавын аңлата бу. Куәте артуын тойган Пекин Америкага тешләрен күрсәтә. Кытай дипломаты Ван И, Мюнхен конференциясе вакытында Европаны янкилардан аерып, үз ягына авыштырырга тырышты, диделәр. Немецларга, французларга, итальяннарга чин базары бик кирәк, шуңа күрә сүзсез генә килешүләрен белдерделәр дигән хәбәрләр дә бар. Ә менә АКШ дәүләт секретаре Блинкен белән Ван Иның ябык ишекләр артында сөйләшүе янкилар көткән нәтиҗәне бирмәгән, дипломатлар үзара ызгышып беткән. АКШның финанс спекуляцияләренә һәм гадәттән тыш күп куллануга корылган икътисады Азия юлбарысы янәшәсендә оттыра. Моны күзәтеп торган дәүләтләр кичекмәстән үзләрендә җитештерү мәсьәләсен хәл итү юлына басарга кирәклекне аңлый.

Кайчандыр сыйфатлы продукция белән дөнья базарларын яулап алган, әмма чиннар тарафыннан өченче позициягә этеп төшерелгән японнар яңа технологик ыргылыш ясау өчен адымнар ясарга җыена. Япон хөкүмәте соңгы көннәрдә генә гыйлемле, бай һәм эшлекле чит ил кешеләрен үз илләренә җәлеп итүнең яңа системасынраслады. Моңарчы Япониядә яшәргә рөхсәт алу катлаулы һәм авыр мәсьәлә иде. Яңа система еллык кереме 20 миллион иенага җиткән (150 мең доллар тирәсе) чит ил тикшеренүчеләренә һәм техник белгечләргә даими яшәү хокукы бирүне күздә тота. Эшмәкәр булсаң, керемең ике тапкыр күбрәк – 40 миллион иена булырга тиеш. Даими яшәү хокукы алган хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына да Япониядә яшәү һәм эшкә урнашу мөмкинлеге бирелә. Экстра-классны белгечләр һәм уңышлы бизнесменнар ил икътисадына этәргеч бирерләр һәм технологик потенциалны үстерерләр дип көтә японнар. Алар ялгышмый кебек.

Шул ук вакытта дөнья рейтингының беренче йөзлегенә кергән уку йортларын (Россиядә андый уку йорты юк) тәмамлаучылар да Япониядә ике елга виза алып эшкә урнаша һәм яши ала башлаячак. Әмма японнарның бу программаны үтәүне кыенлаштыручы проблемалары да бар. Кояш чыгышы илендә компаниягә яңа урнашкан IT белгечләр елга 40 мең доллар гына акча ала. Бу – АКШтагының яртысы, Германиядәгенең 70 проценты. Японнар шулай да чит ил белгечләрен рекрутлау мәсьәләсен чишәргә җыеналар, чөнки икътисадый яктан нык үскән илләр арасында читтән кадрлар китертү буенча алар 25 нче урында гына тора икән. Беренче урында – Австралия, АКШ – җиденче, Германия – 11 нче урында.

Талантлы һәм акчалы кешеләрне илгә җәлеп итү һәр яктан отышлы һәм хәзер модада. Казахстан, мәсәлән, российяләргә үзендә яшәү мөмкинлеген чикләде, әмма игътибар итегез: ай-ти белгечләргә һәм металлургларга даими яшәү хокукын җиңел бирә. Кыргызлар үткән көздә үк «цифрлы күчмә»ләр программасын тормышка ашыра башлады. Программист булсаң, кыргыз шәһәрләрендә күпме телисең, шуның кадәр яши аласың. Дәүләтләр ярыша бу «цифровой кочевник» дигән юнәлештә, IT белгечләрне магнит кебек үзләренә тартырга тырышалар.

Россия программистлары кая барып бөялде, беләсезме? Төркиягә. Әмма декабрь ахырыннан төрекләр озак вакытка яшәү хокукын бирми башладылар диярлек. Шулай да сайлаудан соң төрек хөкүмәтенең дә «цифровой кочевник»ны кертергә җыенуы турында мәгълүмат бар.

Безнекеләр Төркия генә түгел, башка илләргә дә юл тотты. Анда беркем дә юлга җәймә җәеп көтеп тормый, яшәү кыйммәткә төшә, шуңа күрә акчалы һәм акча эшләрлек сәләте булганнар китте. Элекке совет республикаларының икътисадый үсеш темпларын ике урынлы саннар белән арттырды алар. Үзләре белән акча – валюта алып киләләр, җиң сызганып, югары технологияләр өлкәсендә эшлиләр дә. Акчалы кавемнең артуы эчке базарны киңәйтә. Икътисадый үсеш өчен базар кирәк тә инде.

Базарның тараюы Россия өчен зур проблемага әверелеп бара. Әйе, Көнбатыш безгә үз товарларын сатмый, әмма әлегә параллель импорт коткара. Европадан Россия күршеләренә товар агымнары кискен арткан. «Дус» илләр бәя өсти дә безгә сата. Безнең чималны арзанга алалар да, шулай ук бәя өстәп, Көнбатышка саталар. Россиягә «дус ил» булу бик зур бонуслар бирә. Казахстанда, әйтик, акча шулкадәр күбәйде: ел саен һәр балага Милли фондтан 150 доллар акча түли башладылар. Кытай чит ил маркаларының безнең базарны ташлап китүләреннән үзенчә файдалана: безгә саткан машиналарының бәясен 75 процентка кадәр арттырган.

Бу вазгыятьтән чыгарга кирәк бит инде. «Дус» илләр өчен савым сыеры булып ерак китеп булмый, резервлар бервакыт төкәнәчәк. «Импортны алыштыру» дигән сәясәт үзен акламый. Моны башта, «Ватаным Татарстан»га ияреп, Үзәк банк таныды. Үткән тәүлекләрдә генә Путинның вәкаләтле вәкиле Сергей Иванов та: «Полностью производить импортозамещение всего и вся бессмысленно и, я бы даже не побоялся сказать, глупо», – дип әйтте.

Россия сәясәтчеләре соңгы вакытларда гел без «ВТ»да үткәргән фикерләрне кабатлыйлар. Без Кытай юане белән шаярмаска кирәклеген даими әйтеп торабыз. Дәүләт Думасында Икътисадый сәясәт буенча комитет җитәкчесе урынбасары Артем Кирьянов авызыннан да: «Китайский юань не должен быть приоритетной валютой для хранения российских резервов, так как он не был в свободной конвертации и подвержен влиянию политического руководства КНР», – дигән сүзләр төште.

Мәскәүдә базардагы кытлык мәсьәләсен хәл итүнең тагын бер юлын тапканнар кебек. Телеграм-каналларда: «Россия университетларында кире инжиниринг (обратный инжиниринг) буенча белгечләр әзерли башлыйлар», – дигән хәбәр күренде. Фейк түгелдер дип уйлыйм, чөнки 2016 елда ук импортны алыштыру буенча Хөкүмәт комиссиясе утырышында Мантуров әфәнде «кире инженерлык» үзәге булдыру планнары барлыгын әйткән иде. Аның асылы шунда: чит илдә җитештерелгән продуктны аласың да, өйрәнеп, шуның күчермәсен җитештерә башлыйсың. Тукайга ияреп шигырь бозган графоман кебек буласың инде. Сер түгел: графоманныкы Тукайныкы кебек була алмый, пучтәк була. «Обратный инжиниринг» та шундый ук нәтиҗә бирәчәк. Чит ил товарының сыйфатына ирешеп булмаячак. Вакытында Кытай бик файдаланды аны. Чит ил брендларының күчермәсен күпләп җитештерделәр. Сыйфатсыз һәм арзан Кытай товарлары шулай туды. Әммә бездә кытайча булмаячак. Сыйфатсыз һәм кыйммәтле товар төшәчәк конвейердан. Ни өчен шулай икәнен исбатлап күрсәтәбез. Арзан булсын өчен, товарны күпләп җитештерергә кирәк. Дистәләгән миллион данә. Кытайлар шуның белән отты. Бердән, аларның эчке үз базарлары зур, икенчедән, бар дөньяга саталар товарны. Ә Россиянекен алырлармы? Дөресен генә әйткәндә, үсеш юлы түгел бу. Үсеш юлы әнә японча чит ил белгечләрен рекрутлап җигеп эшләтү, берәү дә ясый алмаган технологик товарлар тудыру. Зур базарларга хәзер шулай гына чыгып була.

Беренче чиратта безгә көньякка очкан үз белгечләребезнең илгә кайтуына ирешергә кирәк. Янамыйча, илдә тыныч һәм имин вазгыять тудырып. Санкцияләр чолганышыннан да чыгарга. Бар бит аның юллары, сәяси ихтыяр гына кирәк. Болай «дус» илләргә имезлеккә әверелеп, аларга донор булып, ерак китеп булмаячак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ӘЛМӘТТӘ РӘХӘТРӘК

Кайбыч районы «күк»кә очкан, Актаныш исә упкынга тәгәрәгән. 2022 ел йомгаклары буенча, Татарстан районнары рейтингы билгеле булды. Беренче бишлек үзгәрешсез. Дөрес, «иң-иң»нәр үзара беренчелек өчен көч сынаша. Әлмәт районы быел Казанны да уздырган әнә. Татарстан шәһәрләре һәм районнары ничек яши? Кайсы районнарда тормыш яхшырак? Күрсәткечләрне «ВТ» хәбәрчесе өйрәнде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, республика районнары һәм шәһәрләренең социаль-икътисадый үсеш рейтингын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча, республиканың Икътисад министрлыгы әзерли. Исемлек 45 баскычтан тора. Биредә 43 районнан тыш, Казан һәм Чаллы шәһәрләре дә бар. Рейтингны төзегәндә, төбәктәге уртача хезмәт хакы, кулланышка тапшырылган торак күләме, төп капиталга инвестицияләр, эшсезлек дәрәҗәсе кебек тормышының төрле өлкәләренә караган күрсәткечләр исәпкә алына. Авыл халкыннан гына торган районнарны шәһәр һәм сала кешеләре яшәгән җирлекләрдән аерып тикшерәләр. Саннар гадел булсын өчен шулай эшләнә. Әйтик, Әтнә Казан белән көндәшлек итә алмый, билгеле.

«Алтын» район

Рейтингка ышансаң, Татарстанда иң яхшы тормыш Әлмәт районында булып чыга. Нефть төбәге былтыргы исемлектә өченче булса, быел беренчелеккә чыккан. Узган ел аннан 1,7 триллион сумлык товар төяп озатканнар. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 25 процентка арткан. Былтыр Әлмәт районында алдагы елга караганда 15 процентка күбрәк итеп, 656 миллиард сумлык тулай территориаль продукт җитештергәннәр. Төп табыш нефть икәнен әйтеп-аңлатып та торасы юктыр. Татарстанда былтыр 35,7 миллион тонна «кара алтын» чыгарганнар. Шуның 28,6 миллион тоннасы «Татнефть»кә туры килгән. Район сулышын чагылдыручы тагын бер сан: Әлмәттә былтыр уртача хезмәт хакы, 20 процентка диярлек үсеп, 63 мең 800 сумга җиткән. Татарстан буенча уртача хезмәт хакы исә 54 мең сум тәшкил итә. Ә Балык Бистәсе районында сыер савучы, тракторчылар аена уртача 25 мең сум ала.

Мин дә «кара алтын» өстендә утырсаммы, дип кул селтәргә ашыкмагыз. Кем әйтмешли, байлар да елый. Әлмәтлеләргә якын арада ук җәмәгать транспортына күчеп утырырга туры килмәгәе әле. Баксаң, районда мең кешегә туры килгән автомобильләр саны (542 машина) ил күләмендә иң зурларыннан берсе икән.

– Алга таба да болай дәвам итсә, Әлмәт халкы «бөке»ләрдә буыла башлаячак. Катлаулы хәлдән чыгуның бердәнбер юлы – җәмәгать транспортын үстерү, – ди район башлыгы Тимур Нагуманов.

Беренче бишлек

Узган ел беренчелекне алган Лаеш районы – быел икенче урында. Яшерен-батырын түгел, аны Казанга терәлеп торуы коткара. Шуңа күрә бөтен күрсәткечләр буенча да алдынгылыкны кулдан ычкындырмыйлар. Былтыр, мәсәлән, алдан фаразланганнан ике тапкыр күбрәк итеп – 350 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырганнар. Шуның 98 проценты (!) – шәхси йортлар. Казан янында үз өеңдә яшәү теләге әнә нишләтә! Лаешта эш тә, аш та бар. Татарстанда җитештерелә торган йомырканың 80 проценты бу районга туры килә.

Казан узган ел икенче урында булса, быел – өченче. Башкалада яшәүчеләрнең кесәсе такырайган. Хезмәт хакларын минималь куллану бюджеты белән чагыштырып караганда, узган ел Казанда яшәүчеләрнең сатып алу мөмкинлеге сизелерлек кимегән. Тынычландыру өчен булса да, әйтик: бу хәл ил күләмендә дә күзәтелә. Дөньядагы вазгыять аркасында, бәяләр күтәрелде, ә хезмәт хакы үзгәрергә бик ашыкмый. Казанда торак төзелеше күрсәткече дә 40 процентка диярлек кимегән.

Беренче бишлеккә кергән Тукай һәм Түбән Кама районнарында (быел алар урыннары белән алмашынган. – **Ред.**) да вазгыять тотрыклы. Дүртенче баскычтагы Тукай районы – авыл җирлекләреннән генә торучы төбәкләр арасында да иң яхшысы. Районның төп токкасы – авыл хуҗалыгы. Татарстанда җитештерелгән барлык авыл хуҗалыгы продукциясенең өчтән бере нәкъ менә тукайлыларга туры килә. Районда 16 мең баш мөгезле эре терлек, 290 мең баш дуңгыз, 5,2 миллион тавык, 6 мең сарык һәм 482 ат исәпләнә.

Тик торганнар гына ялгышмый. Түбән Кама районына кагыла торган бу сүзләр. Яхшырак эшләгән саен (ә түбәнкамалылар ел саен рейтингның югары баскычында тора), кимчелекләр дә күбрәк күренә, ахры. Эш шунда ки, соңгы арада республика җитәкчелеге катнашында узган чараларда район башлыгы Рамил Муллинны еш кына тәнкыйтьләп телгә алалар. Татарстан Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы коллегиясендә Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин «глава»га Түбән Камада машина кую урыннары төзү күрсәткече белән килешмәвен әйтте. Татарстан Икътисад министрлыгы коллегиясендә Рөстәм Миңнеханов шелтә белдерде.

– Түбән Кама былтыр алгарышлы үсеш территориясенә бер резидент та җәлеп итмәгән, яңа эш урыннары булдыру планын үтәмәгән. Түбән Кама районы башлыгын күреп, әлеге мәсьәләдә игътибарлырак булырга кирәклеген әйттем инде. Бүгенге шартларда резидентлар табу кыен икәне аңлашыла, әлбәттә. Әмма башкалар булдыра бит, – диде Рәис.

Балтачка ни булган?

Бәхет кояшы былтыр Кайбычка елмайган. Алдагы елда рейтингның иң соңгы баскычында урнашкан район бер ел эчендә 15 нче урынга күтәрелгән әнә. Ничек итепме? М12 югары тизлекле автомобиль трассасы сәбәпче. Билгеле булганча, республика аша узучы яңа юлның озынлыгы 142 чакрым тәшкил итәчәк. Шуның 60 чакрымга якыны нәкъ менә Кайбыч районына туры килә.

– Узган елны бик уңышлы тәмамладык. Өстәмә рәвештә 90 миллион сум табыш алдык. Бу – уртача шәһәрләр өчен дә шактый югары күрсәткеч. Моңа М12 юлы төзелеше бәрабәренә ирештек. Районда өч подрядчы оешма эшли. Аларны вакытлыча Кайбычта теркәлергә үгетләдек һәм салымнарны район бюджетына күчерделәр, – дигән район башлыгы Альберт Рәхмәтуллин.

«Гасыр төзелеше»ндә эшләүче Кайбыч егете Ленар Нигъмәтуллинның кәефе төшкән әле.

– Яңа юлны бигрәк тиз салалар, без озаграк та эшләргә риза, – ди егет. – Районда эш булачак икән дигән хәбәрне зур түземсезлек белән көттек югыйсә. Мин рәсми рәвештә урнашмыйча гына Казанда йөк машинасында эшләдем. Былтыр юл төзелешенә кайттым. Ышанасызмы, Кайбычта икеләтә күбрәк хезмәт хакы ала башладым. Тик яхшы әйбер тиз бетә икән. Зур юлның Татарстандагы өлешен быел ук кулланышка тапшырачаклар, ди.

Кайбыч артыннан Лениногорск һәм Нурлат районнары да югары сикергән. Лениногорскида, мәсәлән, эшсезлек дәрәҗәсе бер ел эчендә 3 тапкырдан да күбрәккә кимегән, төзелеш эшләре 2 тапкыр арткан, авыл хуҗалыгы тармагында күрсәткечләр үскән. Нурлат районы икътисадының саллы өлеше, тәгаен әйтсәк, 62 проценты нефть тармагына туры килә. Былтыр Нурлатта 5,9 миллион «кара алтын» чыгарганнар.

2022 елны зур югалтулар белән тәмамлаучылар арасында беренчелек – Актаныш районында. Ул бер ел эчендә 20 баскычка түбән тәгәрәгән. Районда эшсезлек дәрәҗәсе арту, халыкның сатып алу сәләте киму дә күзәтелгән. Якынча 30 мең кеше яшәгән районда былтыр халык саны 400гә кимегән. Кыскасы, районның яңа җитәкчесенә бурычлар билгеле.

Узган ел Балык Бистәсендә дә җитәкче алмашынды. Аларның да эше күп.

– Күрше Мари Иле белән чагыштырганда, райондагы вазгыять, бәлки, алай ук начар түгелдер. Тик республика районнарын алсак, сезгә әле үсәргә кирәк. Сез тәүлегенә 46 тонна сөт җитештерәсез. Әтнәдә җирләр ике тапкыр азрак, ә савылган сөт күләме 7 тапкыр артык, – диде Рәис районның йомгаклау сессиясендә.

Исемлекнең иң ахырында – Чүпрәле, Арча һәм Балтач районнары. Былтыргы рейтингта Чүпрәле – 33, Арча – 37, ә Балтач 38 нче урында булган. Районнардагы вазгыятьне әнә шуннан чыгып чамалагыз.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫ РЕЙТИНГЫ, 2022 ЕЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Урыны	Район, шәһәр исеме	Үзгәреш
1	Әлмәт	+2
2	Лаеш	0
3	Казан	-2
4	Тукай	+1
5	Түбән Кама	-1
6	Яңа Чишмә	+3
7	Югары Ослан	+1
8	Чаллы	-2
9	Алабуга	+2
10	Питрәч	-3
11	Менделеевск	-1
12	Азнакай	+6
13	Чирмешән	+1
14	Лениногорск	+16
15	Кайбыч	+30
16	Биектау	+4
17	Минзәлә	-4
18	Яшел Үзән	+6
19	Алексеевск	-4
20	Бөгелмә	+3
21	Мөслим	+15
22	Саба	+4
23	Сарман	-4
24	Нурлат	+16
25	Тәтеш	-3
26	Зәй	-5
27	Баулы	+8
28	Мамадыш	-11
29	Буа	-13
30	Чистай	-3
31	Ютазы	-6
32	Актаныш	-20
33	Аксубай	+10
34	Кукмара	-5
35	Кама Тамагы	+7
36	Әлки	-5
37	Әтнә	-4
38	Апас	-6
39	Балык Бистәсе	-11
40	Спас	-2
41	Теләче	0
42	Әгерҗе	+2
43	Арча	-4
44	Чүпрәле	-10
45	Балтач	-8

РЕСПУБЛИКА РАЙОННАРЫНДА УЗГАН ЙОМГАКЛАУ СЕССИЯЛӘРЕНДӘГЕ ЧЫГЫШЛАРДАН

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:

– Чирмешән районы үзәген тәртипкә китерергә кирәк. Сезнең район башкалардан аерылып тора. Эш-көч куюны таләп итүче объектлар да җитәрлек. Бирегә безнең архитектура десантын җибәрергә кирәк. Килсеннәр, карасыннар, киңәшләрен һәм тәкъдимнәрен җиткерсеннәр. Район үзәге матур булырга тиеш дип саныйм.

Фәрит МӨХӘММӘТШИН, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе:

– Әгерҗе районында былтыр 6,97 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылган. Бу – алдан фаразланганның нибары 42 процентын тәшкил итә. Узган ел нәтиҗәләренә караганда, рейтингның 44 нче баскычыннан 41 нче урынга күтәрелгәнсез. Ерак китмәгәнсез, билгеле. Сезнең күпкә яхшырак нәтиҗәләргә ирешкән чакларыгыз да бар иде. Төрле елларда 34 нче урынга кадәр күтәрелдегез. Димәк, мөмкинлекләр бар.

Әсгать СӘФӘРОВ, Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе:

– Хакимиятнең төп бурычы халык ышанычын яулаудан гыйбарәт. Чөнки без аларга хезмәт итәбез. Ни кызганыч, соңгы социологик тикшеренүләрдән күренгәнчә, Бөгелмә районында хакимияткә ышаныч дәрәҗәсе – республика күләмендә иң түбән күрсәткечләрнең берсе... Бөгелмәне ташламаячакбыз!

КЫЕНЛЫКТА КҮРЕНӘ КЫЮЛЫК

Батырлыкка урын һәрчак булды һәм бар. Соңгы арада ирлек белән кыюлыкны сынарлык сәбәпләр аеруча ешайды. Ватан язмышы хәл ителгәндә, ил һәрчак батыр улларына, сабыр халкына таяна бит. Халык та улларын белә, күрә, таный. Онытмаска сүз бирә. Чөнки әле үсеп килүче буынны матур үрнәкләрдә тәрбияләргә, лаеклы алмаш әзерләргә кирәк.

ВАТАН ОНЫТМАС

Махсус хәрби операция башлангач та, егетләребезнең хәрби хәрәкәтләр кырында күрсәткән батырлыклары турында әледән-әле ишетеп тордык. Сокландык, горурландык, кайсыларын – туган җирдә каршы алырга, кайсыларын мәңгелеккә озатырга туры килде...

Дошманга каршы. Лениногорск егете Дамир Исламов – Казан танк училищесы шәкерте. 25 яшьлек егетнең гомере Украинада махсус операция барышында өзелә. Аның экипажы, дошман белән бәрелешкә кереп, биш танктан дүртесен юк итә. Алга таба һөҗүмгә барганда, Дамирның танкы дошман тубы тиеп шартлый. Экипаж, шул исәптән Татарстан егете дә һәлак була. Өлкән лейтенант Дамир Исламовка хәрби бурычын үтәгәндәге каһарманлыгы өчен үлгәннән соң Россия Герое исеме бирелде.

Иң яшь Россия Герое. Казан егете Дамир Гыйлемханов узган елның февралендә махсус хәрби операциягә китә. Егет Дамир Исламов җитәкчелегендәге Т-72Б1 танкын йөртүче-механигы була. Аңа да үлгәннән соң Россия Герое исеме бирелә.

Танкист егет. Дамир Шәймәрданов хәрби операциядә беренче көннән үк катнаша. Ул танкист булып хезмәт итә. Егет апрельдә канкойгыч хәрби хәрәкәтләр вакытында батырларча һәлак була. Аңа да үлгәннән соң Россия Герое исеме бирелә.

Сыналган – сынатмаган. 39 яшьлек Рөстәм Сәйфуллин махсус хәрби операциядә беренче көннәрдән үк катнаша. Аның подразделениесе кичүләрне торгызу белән шөгыльләнә. Ул яу кырында ике тапкыр яралана. Беренчесендә тәненә снаряд кыйпылчыклары кадала. Икенчесендә авыр яралана: бер аягы тездән өзелә, икенчесенең табаны чәрдәкләнә. Әмма ул сугышчыларын калдырып китми. Аның подразделениесе куелган приказны үти: Десна елгасы аша салынган йөзмә күперне дошманның артиллерия утыннан саклап кала. Нәтиҗәдә безнекеләргә алга таба барырга юл ачыла. Мөһим кичүне саклап калуда күрсәткән батырлыклары өчен милләттәшебез «Алтын Йолдыз» медале белән бүләкләнә һәм Россия Герое исеменә лаек була.

Танклар да куркып тора. Раил Габдрахманов хакында шулай диләр. Якташыбыз 10 августта Россия Герое исеменә лаек була. Мәскәүдә аңа әлеге олы бүләкне оборона министры Сергей Шойгу тапшыра. Габдрахманов һәм аның җитәкчелегендәге хәрбиләргә Луганск янындагы бер шәһәрдә күпер төзелешен саклау бурычы куела. Берничә көн дәвамында авыр хәрби техника үтәргә тиешле әлеге җаваплы участокны саклый алар. Төзелеш тәмамлангач, милләттәшебез беренчеләрдән булып елганы кичә. Арсеналда ике танклары була. Дошман тылына үтеп, сугышчан позициягә баса егетләр. Тик төнлә күперне шартлаталар, һәм хәрбиләр ярдәмсез кала. Әкаршы як туктаусыз һөҗүм итә. Бик авыр бәрелеш була бу. «Коткыга бирелмичә, соңгы снарядка кадәр каршы тордык», – ди үзе дә Герой.

САН

Украинадагы махсус операциядә катнашкан 6 якташыбызга Россия Герое исеме бирелде.
Шуларның 3се вафат.
Тагын 52 егет Батырлык орденнары белән бүләкләнде.

АНА ДОГАСЫ

Балтач районының Бөрбаш авылында гомер итүче Мәгъфирә Әсхәдуллина өч игезәк улының икесен махсус хәрби операциягә озаткан. Өлешчә мобилизация башлангач, Балтачта яшәүче ике улына да чакыру килә. Илнар белән Ленарның китәсен белгәч, Казанда яшәүче Динар да теләк белдерә. Әмма аны кире боралар.

– Улларым армиядә өчесе бергә хезмәт иттеләр. Аларның үз тормышы инде. Илнар белән Ленарның исән-сау кайтуын Аллаһы Тәгаләдән гел сорыйм. Илнарым яраланган әле. Аякларына зыян килгән. Мәскәүдә дәвалана. Ленар әлегә тынычрак урында ял итә. Икесе дә: «Әни, борчылма!» – дип тынычландыра, – ди Мәгъфирә апа. – Ничек кайгырмыйсың?! Шул балаларымны бер үзем аякка бастырган кеше бит мин! Улларым белән бик горурланам. Ана өчен иң зур хис шушы инде. Лачындай егетләр үстергәнмен икән. Бик тәртипле булдылар. Өлешчә мобилизация башлангач та, бармыйбыз, дип тормадылар. Хәрби комиссариаттан шалтыратуга, китәргә әзерләнә башладылар. Барысы да Ватан хакына бит. Илебез тынычлыгы өчен китте бит алар.

Мәгъфирә апа гел догада тора. Ана догасының көченә ышана ул.

– Илгә килгән борчу бит. Безгә елап утырырга ярамый. Улларын көтүче әниләргә сабырлык телим. Күңелем сизә: балаларыбыз җиңү белән кайтачак, – ди Мәгъфирә апа.

kvtkku.mil.ru

ДӨРЕС ЮЛДА

Ватаныбыз сагында торган, илебез мәнфәгатьләрен кайгырткан каһарманнарны тагын бер кат олылау, искә алу көне. Татарстаннан махсус хәрби операциядә катнашкан бердәнбер депутат Эдуард Шәрәфиев 23 февраль – Ватанны саклаучылар көненең иң төп асылы дип әнә шуны атый. Хәтерләсәгез, узган елның ноябрендә Эдуард Шәрәфиев үз теләге белән махсус хәрби операциягә киткән иде. Күптән түгел депутат өенә кайтты. Аның өч айга төзелгән контракты тәмамланган.

Эдуард Шәрәфиев быелгы бәйрәмне икеләтә дулкынлану белән каршылавын яшерми.

– Ил-көндә барган вакыйгалар бу көнгә үзгә төсмер өсти, аның мәгънәсен тагын да көчәйтә. Бу бәйрәмгә хәзер аеруча җитди карыйбыз. Ул ел әйләнәсендә өстәмә ял бирә торган гади бәйрәм көне генә түгел. Ватаныбыз сагында торган, илебез мәнфәгатьләре сагында торучыларны олылау, искә алу көне. «Ватан», «батырлык», «каһарманлык» төшенчәләренең дә кыйммәте, кадере артты, – ди депутат.

Эдуард Шәрәфиев сүзләренә караганда, махсус хәрби операция зонасында булып кайтканнан соң, башкарган эшләребезнең хаклыгына, дөрес юлда булуыбызга тагын бер кат инанган ул.

– Андагы егетләребез кемнәргә каршы торуыбызны да, безгә кемнәрнең каршы чыгуын да бик яхшы аңлый. Дошманнар кулында – заманча техника, заманча технологияләр, заманча корал. Безнең каһарманнарыбызда исә – рух ныклыгы, җиңүгә омтылыш. Әмма илебезнең күпьеллык тарихы шуны күрсәтә: Көнбатыш үзенең заманча кораллары белән безгә ничек кенә каршы чыкса да, безне җиңә алмый, – ди депутат.

СОЛДАТЛАР ӘТИСЕ

Аларга туган яктан килгән кәгазь кисәге дә кадерле. Әти-әниләре җибәргән ризыклардан өй исен, җылы оекбашлардан йөрәк җылысын тоялар. Махсус операциядәге егетләр бөтен республика халкына рәхмәтле. Анда «синеке», «минеке» дигән сүз юк. Бары бергә, югы уртак! Егетләргә ярдәм җыеп, аларны кулларына илтеп тапшыручы волонтерлар исә туган яктан сәлам һәм куәтәнәч кенә түгел, өмет тә алып килүчеләр.

Мамадыш районында яшәүче эшмәкәр Фәнил Гыйззәтуллин Казан Кремлендә Рөстәм Миңнеханов кулыннан «Фидакарь хезмәт өчен» медале алгач, йөзләгән кеше аңа янә рәхмәт сүзләре язып калдыра. Күбесе – солдат әниләре. Ни әйткәннәрен беләләр. Фәнил абый, халыктан җыелган әйберләрне машиналарына төяп, Ватанны сакларга киткән егетләргә илтеп бирә, аларның күңелен күрергә тырыша.

– Мин дә – хәрби операцияләрдә катнашкан кеше. Күпне күрдек, бердәм булдык. Элемтә юк иде. Әнием алты ай бүе миннән хәбәр көтеп яшәде. Кайтмас дигән булганнар. Гомерем бетмәгәч, кайттым. Егетләр дә кайтачак, – ди ул. – Яшь-яшь егетләр Ватанны саклаганда, нинди йөрәк белән тыныч кына яшәргә кирәк?! Мин – болай да тынгысыз кеше. Тәртипсезлек яратмыйм. Дөреслек булсын дип йөрим.

Фәнил абыйга – 51 яшь. Балаларым күп минем, ди ул. Баксаң, янындагы бар балага да «улым», «кызым» дип дәшә икән. Әле бервакыт кызык хәлгә дә калган.

– Гуманитар ярдәм җыйдык та, илтергә үзем бара алмадым, – ди ул. – Йөкне озатып кайтсам, исемләп җибәрелгән бер посылка онытылып калган. Нишләргә? Тизрәк урамга чыктым. Бер кеше очрады. Ярдәмне төяп озаткан машинаны куып җитәргә кирәк, улыма дигән посылка калган, дим. Риза булды. Сөйләшеп киттек. Баксаң, аның улы да хәрби операциядә икән. Исем-фамилиясен дә әйтте. Мин «улым» дип атаган, посылкасы онытылган егетнең әтисе булып чыкмасынмы!

Фәнил абый әйтүенчә, егетләргә бар кирәк-яракны ташыйлар икән. Күбрәк тәм-том алып барырга тырышалар. Җиһазлар ясап бирүчеләр дә бар.

– Үзенә тигән кешегә бик кыен, башкалар моны аңлап та бетермәскә мөмкин, – ди Фәнил абый. – Район хакимияте белән берлектә эшлибез. Һәрберсен яхшы итеп киендереп озаттык. Бөтенесе белән элемтәдә торам. Нәрсә сорасалар, шуны илтәбез. Район фермерларына, эшмәкәрләренә, дин әһелләренә, хатын-кызлар оешмасына, мәктәпләргә чиксез рәхмәт. Беркем дә читтә калмый. Берәү оекбаш китерә, икенчесе акчасын суза. Әле менә бер абый килде. «Фәнил, мин егетләргә берничек тә ярдәм итә алмыйм. Әмма «УАЗ»игым бар. Шуны бирәм, каратып ал», – ди. Бумы инде ярдәм итә алмау! Егетләр бик сөенәчәк. Без бердәм икәнебезне тагын бер кат расладык. Монда без рәхәттә яшибез. Андагы хәлләрне барып күрергә кирәк. Әмма миндә курку юк. Аллаһы Тәгалә биргән гомерне яшибез, дип йөрим. Хатын курка инде. Йөрмә, ди. Тик мин ничек инде балаларым яшендәге егетләрне ташлый алыйм? Ярдәмем кирәк чакта барачакмын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА, Динә ГЫЙЛАҖИЕВА, Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИЛЕҢ ТУРЫНДА УЙЛА

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК НИДӘН БАШЛАНА?

Ватан, батырлык, патриотизм сүзләренең асыл мәгънәсенә төшенергә тырышып яшәгән көннәребез. Әле алар белән янәшә горурлану, ярату, хөрмәт итү дигән фигыльләр дә йөри. Берсе дә начар сүз түгел, билгеле. Ә шулай да, ватанпәрвәрлек дигән абстракт төшенчәгә без хәзер нинди мәгънә салабыз соң?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җәмгыять берләште

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләренең быелтыр уздырган сораштыру нәтиҗәләренә күз салыйк әле. Сораштыруда катнашучыларның 92 проценты үзләрен бу илнең патриоты дип атаган. Респондентларның 50 проценты патриотизм сүзенә иң элек ватанга мәхәббәт мәгънәсен сала икән. Чикләүләр һәм Россиягә карата булган тискәре мөнәсәбәт чын патриот үз илен якларга тиеш дип уйлаучылар санын да арттырган. 2022 елда андыйлар 44 процентка җиткән. Чагыштыру өчен, 2020 елгы санга күз салу да җитә: ул чорда андыйлар 32 процент булган.

Моннан тыш сораштыруда катнашучыларның 34 проценты патриот булу ил киләчәген үзгәртергә тырышу дип уйлый икән. 29 проценты ил турында дөресен сөйләргә кирәк дигән фикердә. Ул хакыйкать нинди генә ачы булса да.

Ватанпәрвәрлек хисен арттыруга илкөн вакыйгалары да тәэсир итә. Әйтик, сораштыруда катнашучыларның 18 проценты Кырым күпере, тагын 18 проценты – Россия составына яңа территорияләр кушылуы, 8 процентын Россия спортчыларының уңышлары һәм 5 проценты икътисад үсеше, импортка алмаш юнәлешендәге эшчәнлек белән горурлана икән.

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү үзәгенә ярдәм итү фонды генераль директоры Константин Абрамов фикеренчә, Россиядә үзен патриот дип санаучылар саны арткан. «Соңгы арада мондый кешеләрнең проценты, хәтта яшьләр арасында да, сизелерлек артты. Санкцияләр, дөньядагы башка вакыйгалар фонында халыкның хөкүмәт һәм ил Президентының эшчәнлеген хуплаучылар яисә хупламаучылар санын ачыклау мөһим. Шулай ук җәмгыятьнең берләшүе күзәтелде», – ди Константин Абрамов.

Без патриотмы?

Илне сакларга, якларга һәм яратырга дип антлар биргән кешеләргә бу сорауны махсус бирмәдек. Ватанпәрвәрлек дигән хис булмаса, алар мондый ант бирмәс тә иде бит, шулаймы? Тормышта ватанпәрвәрлеккә урын бармы? Без шул хакта көндәлектә патриотизм чаткылары эзләгән һәм тудырган кешеләрдән сораштык.

Гыйрак егете Аммар Хөсәйн өчен Россия чит ил түгел. Бирегә күченеп, монда укып кына калмыйча, киләчәк тормышын да безнең ил белән бәйләргә тели ул. Россиядә, аерым алганда, Казанда яши башлавына да 8 ел булган инде. Илгә мәхәббәтен хезмәте белән күрсәтә. Ул табиб булачак. Моңа кадәр ил кичергән бер генә вакыйгадан да читтә калмады ул. Волонтер булып та йөрде, көнне-төнгә ялгап «кызыл зона»да да эшләде, гуманитар ярдәм оештыруда да катнашты.

> Мин – чын патриот. Көннән-көн бу илгә булган мәхәббәтем арта. Россия бик матур ил. Бирегә мин күп нәрсәгә өйрәндем, монда дусларым, җаныма якын кешеләрем бар. Алар миңа бер генә мизгелгә дә үземне чит итеп тоярга мөмкинлек бирмәде. Үз иттеләр, яраттылар, терәк булдылар. Алар дигәндә Россиянең халкын күз уңында тотам. Россия – көч, мәхәббәт һәм мәрхәмәтлелек ул.

Татарстандагы үзбәкләрнең милли-мәдәни автономиясе активисты Таманно Уразова да үзен бу илнең ватанпәрвәре дип саный. Күп нәрсәгә өйрәтте, мөмкинлекләр бирде бу ил, ди ул.

– Мин патриотизм төшенчәсен сәяси юнәлештә түгел, күбрәк мәдәни-рухи яктан аңлыйм. Минем өчен тәрбия һәм мәдәният төшенчәләре үзара тыгыз бәйләнгән. Илнең мәдәни компонентлары миндә ватанпәрвәрлек хисен уята. Мин – иҗат кешесе. Шуңа күрә дә мин безнең илнең безгә кадәр килгән буыннары нинди корганына, нинди булдырганына карыйм, болар – горурланырга сәбәп. Алар мине илһамландыра. Мин меңәрләгән еллар дәвамында буыннан-буынга тапшырылып килгән ул кыйммәтләрне киләчәккә тапшырырга әзер. Берзаман: «Илдә патриотизм күбрәк булган саен, халыкның яшәү дәрәҗәсе шулкадәр түбәнрәк», – дигән сүзләр ишеттем. Моның белән бер дә килешмим. Алга киткән бик күп дәүләтләрне беләм, аларның күбесенең нигезендә ватанпәрвәрлек ята. Россиядә дә патриотлар күп дип уйлыйм. Чит илләргә чыккач, Россия гражданины паспортын күрсәтергә оялган кешеләрне беләм. Минем беркайчан да алай иткәнем юк. Кызыл паспортны һәрвакыт горурланып күрсәтәм, – ди ул.

Таманно әйтүенчә, аның өчен патриотизм – үзеңнеке дип саналган илгә булган эчкерсез мәхәббәт һәм рәхмәт хисләре. «Берәр нинди бәхәс килеп чыкканда, бармак төртеп күрсәткәндә үз илеңне яклап чыга алу да – ватанпәрвәрлек. Тетрәндергеч, бай тарихы белән горурлану да – ватанпәрвәрлек. Патриотизм – әле шушы илнең көченә, бөтен авырлыкларны җиңә алачагына ышаныч та», – ди ул.

Блогер Ринат Галиәхмәтов иң элек патриотизм үзеңә тугрылыкта да чагылырга тиеш дип саный. Ягъни кемдер кушкан өчен генә патриот булып булмый. Шул ук вакытта һәр нәрсәгә карата да ватанпәрвәрлек хисләрен кичерергә мөмкин.

– Кечкенә чактан ук безне «патриот бул» дип өйрәтәләр бит инде. Әмма без бу сүзне кем өчендер генә әйтергә тиеш түгел. Бу дөрес түгел. Ватанга карата патриот булу – бер нәрсә, ә сәясәткә карата булганы – бөтенләй башка. Ватан сүзенә синең телең, кешеләр, табигать тә керә. Сәясәт белән бер дулкында булсаң, аны да патриотизмга кертәсең инде, – ди блогер. – Мәсәлән, мин – Түбән Кама егете. Казанда яшим. Әйтик, минем өчен «Ак барс» хоккей клубы беренче урында булырга тиештер инде. Тик юк бит! Мин «Нефтехимик» өчен җан атам. Менә шундый кечкенә нәрсәләрдә дә патриотизм чагыла ала дип уйлыйм. Патриотизм – синең эчке халәтең ул.

Россия мәктәп укучылары хәрәкәтенең төбәк бүлеге координаторы Руфина Раззакова фикеренчә, хәзерге җәмгыятьтә патриотизм сүзе төрле кешедә төрле хис тудыра.

– Безгә мәктәп эскәмиясеннән Ватанга мәхәббәт һәм бурыч хисе тәрбияләделәр, әмма бу төшенчәләр күпчелектә бүгенгә кадәр формальләшмәгән. Минемчә, иң беренче чиратта мәхәббәт һәм патриотизмның нәрсә икәнен аңлатырга кирәк. Бу сыйфатлар нәрсәдә күренә, аларны ничек кичерергә кирәк? Тирән, җентекле аңлатма аша гына үз Ватаныңы чын-чынлап яратырга өйрәтеп була. Идеология аңлаешлы массакүләм булудан битәр, аңлаешлы булырга тиеш, – дигән фикердә ул.

Татарстанның яшьләр эшләре буенча министры урынбасары Алла Кондратьева, яшьләр арасында патриотик тәрбия чаралар аша да алып барыла, ди.

– Патриотик тәрбия дибез икән, бу бит әле хәрби патриотиканы күздә тоту түгел. Бу – шәхес үсеше өчен иҗади һәм интеллектуаль тәрбия эше дә. Татарстанда яшьләргә патриотик тәрбия бирү программасы эшли. Узган елда гына да без 184 меңнән артык кешене колачлап, 42 зур чара уздырдык, – ди урынбасар.

Тотып карарга, катнашырга мөмкин булганнары да бар чаралар арасында. Әйтик, хәрби-патриотик клуб слетлары, 10 сыйныф укучылары өчен хәрби җыеннар, махсус эзләү отрядлары экспедицияләре, тарихи вакыйгаларны реконструкцияләү.

Соңгы сүз урынына

Шунысы бәхәссез: ватанпәрвәрлек көчләп таккан идеология булырга тиеш түгел. Идеология ул – барыбер дә мәҗбүриләп тагыла торган күренешләрдән. Көчләп яраттырып булмый бит барыбер. Ул нәфрәт, ярсу гына уятачак. Ярату ихлас булганда гына нәтиҗә бирә. Ә без матур нәтиҗәләр генә күрергә телибез. Шуңа да идеологиядән битәр дөньяга караш (мировоззрение) белән эшләргә кирәктер. Анысын аңда формальләштыру, дөрес нигезгә орлык итеп чәчәргә дә мөмкин. Бездә дөрес юнәлеш бирердәй үрнәкләр юкмы әллә? Ватанпәрвәрлек – хис ул.

Аннан, еш кына: «Ватанпәрвәрлектән башка илдә яшәүчеләрне берләштерүче бүтән идея була алмый», – дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Аеруча хакимияттән, җитәкчеләрдән. Бу җәһәттән ярату ике яклы булганда гына бөтен һәм тулы диясе килә бит әле…

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы:

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) үз хәдисендә: «Ватанны ярату – иманнан», – ди. Без Ватаныбыз, туган җиребезне яратырга гына түгел, якларга да тиеш. Бер үк вакытта һәркем аны үзенчә саклый. Кемдер бу бурычны дога кылып, кемдер кулына мылтык алып, кемдер балаларга патриотик тәрбия биреп башкара. Хәрби хезмәткә бару, Ватанны яклау ислам дине күзлегеннән – саваплы эш.

Бу – кызык!

- Күренеш буларак патриотизм Борынгы Греция, данлыклы Гомер яшәгән чорга барып тоташа, ди күп кенә галимнәр. Бу вакытта безнең чорга кадәр килеп җиткән героик эпослар, Борынгы Греция каһарманнары турында миф һәм риваятьләр барлыкка килә. Танылган дәүләт эшлеклеләре, фәлсәфәчеләр, хәрбиләр әнә шул рухта тәрбияләнә.
- Яңарыш чорында күп кенә дәүләтләрдә рухи-әхлакый яктан бай гражданин-кешене тәрбияләү алга чыга.
- XVIII–XIX йөзләрдә патриотизм яңа төсмер алып, сәяси-хокукый лексиконга кереп китә.

Клиник психолог, табиб-психофизиолог Андрей ДЕМКИН:

Гаилә моделенә күз салыйк: атаны, ананы, абый-апа, эне-сеңелләрне яратырга өйрәнеп буламы? Мәхәббәткә нигезләнгән чын патриотизмны (башкаларга карата нәфрәт һәм кимсетүгә нигезләнгән трайбализмнан аермалы буларак) тәрбияләү яки аңа өйрәтү мөмкин түгел.

Мәхәббәткә кайгырту аша (ашату-эчертү, үсеш һәм физиологик ихтыяҗларны канәгатьләндерү, рухи теләкләренә теләктәш булу) лаек булырга мөмкин. Мондый мәхәббәткә «патриотлык дәрес»ләре кирәк түгел.

27 февраль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 16.00 «СИҢА КАЙТАМ» 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». Телесериал 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 16+
19.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
23.50 «Здоровая семья: мама,папа,я» 12+
00.05 «Если хочешь быть здоровым» 16+
00.40 «Ком сәгате» 16+
01.30 «Чёрное озеро» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». Телефильм 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.05, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Долгожданная премьера. В эфире «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Премьера. «Век СССР». 1-я серия. «Восток» 16+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Валерия Федорович, Маруся Климова, Надежда Лумпова, Алексей Демидов, Михаил Евланов, Владимир Кошевой. «ЛИМИТЧИЦЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
00.05 Премьера. «Новороссия». Фильм Андрея Медведева 12+
01.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
03.00 Елена Яковлева. «КАМЕНСКАЯ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. One FC. Джон Линекер против Фабрисио Андраде. Трансляция из Таиланда 16+
07.00, 12.55, 14.20, 22.55 Новости
07.05, 22.10, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.20, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.40 Спортивный дайджест 0+
11.40, 04.00 Еврофутбол. Обзор 0+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
14.25 Футбол. FONBET Кубок России. 1/4 финала. «Звезда» (Санкт-Петербург) – «Пари НН» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
16.30 Футбол. FONBET Кубок России. 1/4 финала. «Урал» (Екатеринбург) – «Ростов» (Ростов-на-Дону). Прямая трансляция
19.00 Футбол. FONBET Кубок России. 1/4 финала. «Спартак» (Москва) – «Локомотив» (Москва). Прямая трансляция
23.00 Церемония вручения наград «The Best FIFA Football Awards 2022». Прямая трансляция из Франции
01.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «Зенит» (Санкт-Петербург) 0+
03.25 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
03.55 Новости 0+
04.50 Лыжный спорт. Фристайл. Акробатика. «Кубок чемпионов». Трансляция из Москвы 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сергей Жарков в остросюжетном детективе «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.40 Сериал «А.Л.Ж.И.Р.» (S) 16+
03.20 Фильм «БИТВА» (S) 6+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.25 «Давай разведёмся!» 16+
09.30 «Тест на отцовство» 16+
11.40 «Понять. Простить» 16+
12.45 «Порча». «Страх ночи» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «Голоса ушедших душ» 16+
15.05 «ВТОРОЙ БРАК» 16+
19.00 «БЛОНДИНКА И БРЮНЕТКА» 16+
23.15 «Голоса ушедших душ» 16+
23.50 «Порча» 16+
00.25 «Знахарка» 16+
01.00 «Верну любимого» 16+
01.35 «ДОЛГИЙ СВЕТ МАЯКА» 16+
04.50 «6 кадров» 16+
05.05 «Понять. Простить» 16+
05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

04.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ». 1-я – 3-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.15 «СЛЕД СОКОЛА» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.35, 15.05 «ОДЕССИТ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Документальный сериал. 1-я серия 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Роберт Ханссен – самый хитрый агент КГБ» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ЛАРЕЦ МАРИИ МЕДИЧИ» 12+
03.05 «Ангелы с моря». Документальный фильм 12+
03.50 «ОДЕССИТ». 1-я и 2-я серии 16+

28 февраль | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». Телесериал (Россия, 2012) 12+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». Телесериал 12+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Соотечественники» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00, 22.10 «Трибуна «Нового Века» 16+
00.20 «Видеоспорт» 16+
00.45 «Соотечественники». Юнус Ахметзянов. Повар национального масштаба 16+
01.10 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
01.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.35 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». Телефильм 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Долгожданная премьера. В эфире «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «Век СССР». 2-я серия. «Север» 18+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Валерия Федорович, Маруся Климова, Надежда Лумпова, Алексей Демидов, Михаил Евланов, Владимир Кошевой. «ЛИМИТЧИЦЫ» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Елена Яковлева в телесериале «КАМЕНСКАЯ» 16+
03.45 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Никита Крылов против Раяна Спэнна. Трансляция из США 16+
07.00, 18.55, 22.35 Новости
07.05, 14.00, 16.30, 19.00, 21.30, 00.45 Все на Матч! Прямой эфир
10.20, 03.35 Специальный репортаж 12+
10.40 Лыжные гонки. «Чемпионские высоты». Женщины. 10 км. Прямая трансляция из Архангельской области
12.35 Художественная гимнастика. Чемпионат России. Финалы в отдельных видах. Прямая трансляция из Москвы
14.25 «Ты в бане!» 12+
14.55 Самбо. Чемпионат России. Прямая трансляция из Перми
16.55 Церемония вручения наград «The Best FIFA Football Awards 2022». Трансляция из Франции 0+
18.25 «География спорта. Краснодар» 12+
19.25 Футбол. FONBET Кубок России. 1/4 финала. «Краснодар» – ЦСКА. Прямая трансляция
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Торино». Прямая трансляция
01.25 Лыжные гонки. «Чемпионские высоты». Женщины. 10 км. Трансляция из Архангельской области 0+
03.05 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
03.55 Новости 0+
04.00 «Третий тайм» 12+
04.30 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. 1/4 финала. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Пермские медведи» (Пермь) 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Остросюжетный сериал «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР» (S) 16+
22.00, 00.00 Боевик «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.40 Сергей Горобченко. «ЧУЖОЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.45 «Давай разведёмся!» 16+
08.50 «Тест на отцовство» 16+
11.05 «Понять. Простить» 16+
12.10 «Порча». «Сломанный компас» 16+
12.40 «Знахарка» 16+
13.15 «Верну любимого» 16+
13.50 «Голоса ушедших душ» 16+
14.25 «Скажи, подруга» 16+
14.40 «ЮРОЧКА» 16+
19.00 «БЕДНАЯ РОДСТВЕННИЦА» 16+
23.15 «Голоса ушедших душ» 16+
23.45 «Порча» 16+
00.20 «Знахарка» 16+
00.55 «Верну любимого» 16+
01.25 «В ОТРАЖЕНИИ ТЕБЯ» 16+
04.40 «6 кадров» 16+
04.50 «Понять. Простить» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ОДЕССИТ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.15 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.45, 15.05 «ВИКИНГ-2». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Битва коалиций. Вторая мировая война». Документальный сериал. 2-я серия 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ТРАКТИР НА ПЯТНИЦКОЙ» 12+
02.55 «Тамерлан. Архитектор степей». Документальный фильм 12+
03.40 «Москва фронту». Документальный сериал 16+
04.00 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 1-я и 2-я серии 16+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗӘК САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ

21 февраль, 2023 ел Казан ш. № 9/53

20 нче Электротехника бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлауны билгеләү турында

20 нче Электротехника бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләренең вакытыннан алда тукталуына бәйле рәвештә, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 71 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 104 статьясындагы 1, 2 өлешләре нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Коробченко Олег Владимировичның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында» 15 июнь, 2022 ел, №1458-VI ГС Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына туры китереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе **карар бирә**:

1. 20 нче Электротехника бер мандатлы сайлау округында бер мандатлы сайлау округы буенча алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлауны 2023 елның 28 маена билгеләргә.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Бу карарны «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе А.С. Кондратьев

Татарстан Республикасы
Үзәк сайлау комиссиясе Секретаре Н.П. Борисова

Белдерү

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.: +79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, ул. Ново-Аракчинская, д. 17 с кадастровым номером 16:50:280714:68.

Заказчиком кадастровых работ является Бураев Альберт Рафаилович (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11. Тел.: +79272414666.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 3 апреля 2023 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 1 марта 2023 г. по 1 апреля 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 1 марта 2023 г. по 1 апреля 2023 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:280714:3 (Республика Татарстан, г. Казань, Кировский район, ул. Ново-Аракчинская, дом 15).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007г. №221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Кадастровым инженером Хабибуллиным Ильдаром Ибрагимовичем (номер квалификационного аттестата кадастрового инженера 16-14-724, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д.11, 420107, ildarkhabib@mail.ru, тел.:+79272414666, номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляемых кадастровую деятельность 31944) проводятся кадастровые работы в отношении земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, п. Плодопитомник, ул. Клубничная, д. 6 с кадастровым номером 16:50:160602:396.

Заказчиком кадастровых работ является Гильмутдинов Зуфяр Нурмиевич (контактная информация: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11. Тел.: +79272414666).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11 3 апреля 2023 г. в 10.00 ч.

С проектом межевого плана можно ознакомиться по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д.11.

Требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 1 марта 2023 г. по 1 апреля 2023 г., обоснованные возражения о местоположении границ земельных участков после ознакомления с проектом межевого плана принимаются с 1 марта 2023 г. по 1 апреля 2023 г. по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Тихомирнова, д. 11.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:160602:1472 (Республика Татарстан, г. Казань, ул. Раушан, д. 3).

При проведении согласования местоположения границ при себе иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. №221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

МӘКЕРЛЕ МАЙ

Соңгы өч дистә ел вакыт эчендә Җир йөзендә симерүдән интегүчеләр саны ике тапкыр арткан. Юкка гына белгечләр аны замана чире дип атамый инде. Симерү елдан-ел яшәрә бара, дип тә чаң суга алар. Симерү белән артык авырлыкның чиге кайда? Йокысы туймаган кеше симерә диюләре дөресме?

vk.com

Табиб-эндокринолог Динара ТАЮПОВА белән шул сорауларга җавап эзләдек.

:: Ни өчен симерү замана афәтенә әверелеп бара?

– Беренчедән, бүген без чамадан тыш күп ашый башладык. Соңгы арада кешенең көнлек рационы уртача 40 процентка артты. Шул ук 1960 нчы еллар белән чагыштырсак та, аерма – җир белән күк арасы. Кушылган шикәр, икенче төрле әйтсәк, җиңел углеводларга бай ризыкларга өстенлек бирүебез дә артык авырлыкка китерә. Халыкның фастфуд кебек берничә кат эшкәртелгән, составында трансмайлар булган ризыкка мөкиббән китүе дә яхшыга түгел. Болар бар да организмдагы матдәләр һәм углеводлар алмашын боза. Соңгысы, симерүдән тыш, бик күп чирләрнең башлангычы да булырга мөмкин. Күреп торабыз: соңгы арада кешегә хәрәкәт җитми. Күпләр җиңел машинага күчеп утырды. Болар да, үз чиратында, симерүнең торган саен ныграк тамыр җәюенә этәргеч булды.

:: Артык авырлыгың барлыгын ничек белергә?

– Моның гади генә формуласы бар. Аны ачыклау өчен гәүдә авырлыгын озынлыгының (метрларда) квадратына бүләргә кирәк. Аны тагын берничә ысул белән дә ачыклап була. Әйтик, корсак һәм бил турысындагы май катламы 2 сантиметрдан артып китсә, артык авырлыктан шикләнергә җирлек бар. Хәзерге вакытта кешенең артык авырлыгы бармы-юкмы икәнлекне төгәл ачыклаучы махсус җиһазлар да кулланыла. Алар май катламын гына түгел, мускуллар авырлыгын да, организмда тоткарланган су күләмен дә үлчи.

:: Коронавирус белән авырып терелүчеләр арасында: «Ковидтан соң кисәк кенә тазардым. Гел ашыйсым килеп тора», – дип зарланучылар күп. Симерү белән коронавирус арасында нинди бәйләнеш бар?

ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

✓ Дөрес тукланыгыз. Көндәлек рационыгыз файдалы матдәләргә, витаминнарга бай булсын.
✓ Көненә дүрт-биш тапкыр аз-азлап ашау хәерле.
✓ Йокы режимын бозмагыз. Сәламәт булу өчен кеше кичке сәгать уннан да соңга калмый йокларга ятарга тиеш.
✓ Һәрчак хәрәкәттә булып, физик активлык турында да онытмагыз. Җәяү йөрү артык авырлыктан гына түгел, бик күп чирләрдән коткара. Шунысын да онытмагыз.

– Бу, иң беренче чиратта, коронавирусны дәвалау алымнарына бәйле. Билгеле булганча, ковид йоктырган кешегә гормональ препаратлар билгеләнә. Алар углеводлар алмашын акрынайта. Аннары коронавирус иммунитетны эштән чыгара. Организм витаминнарга, микроэлементларга кытлык кичерә. Тора-бара ул шушы бушлыкны җиңел углеводлар ярдәмендә тутыра башлый. Кешенең гел ашыйсы, бигрәк тә камыр ризыкларыннан авыз итәсе килеп тора. Шул рәвешле кешенең гәүдә авырлыгы да зур тизлек белән арта. Шуңа күрә коронавирус белән авырып терелгән кешеләргә, тернәкләнеп килгән чорда гына булса да, дөрес туклануга күчәргә киңәш ителә.

:: Симерү кайсы чирләр турында кисәтә?

– Симерү аркасында кешедә йөрәк-кан тамырлары авырулары, атеросклероз, үт куыгында таш, үт куыгы ялкынсыну (холецистит) кебек чирләр дә пәйда булырга мөмкин. Симерүдән интеккән кешенең бавыры чамадан тыш зур күләмдәге май һәм углеводларны эшкәртеп өлгерә алмый. Шул рәвешле бавыр күзәнәкләре үзләре дә – май күзәнәгенә, ә бавыр май күзәнәкләре җыелмасына әверелә. Тора-бара ул бавыр циррозы ук китереп чыгарырга мөмкин. Май күзәнәкләре бик тиз ялкынсына. Бу исә организмда яман шеш тә пәйда булырга мөмкин дигән сүз. Күптән түгел галимнәр симерүнең 13 төрле яман шеш авыруына сәбәпче була алуын ачыклаган.

:: Баласы артык авырлыктан интеккән ата-аналар еш кына үзләрен: «Үсәч ябыга ул. Үсмерлек чорына җиткәч, артык авырлыгының эзе дә калмаячак», – дип тынычландыра. Бу сүзләрдә хаклык бармы?

– Ул чорда бала, киресенчә, тагын да тазарырга мөмкин. Ник дигәндә, үсмерлек чорында балаларда инсулинга сизгерлек кими. Ул, гадәттә, җенси өлгерү чорында башлана һәм артык озак дәвам итми. Шушы чорда бала кисәк кенә тазарырга, артык авырлык җыя башларга мөмкин. Бу вакытта ата-ана дилбегәне тиз арада үз кулына алырга тиеш. Иң беренче чиратта, баланың туклануын контрольдә тотарга кирәк. Ул дөрес тукланырга, вакытында йокларга ятып, вакытында торырга, спорт белән шөгыльләнергә тиеш. Болар бар да зур үзгәрешләр барган яшь организмны симерүдән саклап калачак. Гомумән, баланы тукланудан кечкенәдән үк дөрес тукланырга өйрәтергә кирәк. Нәселендә артык авырлык, симерүдән тилмергән кешеләр булса, моңа бигрәк тә игътибарлы булу сорала.

:: Симерү йокы режимы бозылу аркасында пәйда була аламы?

– Әлбәттә, була ала. Симерүнең сменалы эштә эшләүчеләр арасында ешрак очравы да, нигездә, нәкъ менә шушы йокы режимы бозылуга бәйле. Кеше вакытында йокламый, вакытында тормаса, организмда мелатонин гормоны тиешле дәрәҗәдә бүленеп чыкмый. Бу гормон җитмәгәндә матдәләр алмашы начарая. Төнге өчкә-дүрткә кадәр йокламаучылар кортизол исемле стресс гормоны хисабына яши. Ул инсулинны киметә. Бу исә, үз чиратында, кандагы шикәр күләме артуга китерә.

:: Интернет челтәрендә: «Бер атна эчендә 30 килограмм авырлыктан котыласың»ише игъланнар гел күзгә ташлана...

– Нинди генә диета булмасын, кеше аны табиб белән киңәшләшкәч кенә тота башларга тиеш. Соңгы арада бик популяр булган төрле марафон, мастер-классларда бирелгән киңәшләргә, интернетта язылганнарга таянып ябыгырга маташу – зур хата. Алар сәламәтлеккә зур зыян салырга мөмкин.

Артык авырлыгың бармы?

Ничек исәпләнә?
Гәүдә авырлыгы: (буй озынлыгы × буй озынлыгы) = гәүдә массасы индексы.
Мисал:
65 : (1,76 × 1,76) = 20,98 (нормаль авырлык)
Гәүдә массасы индексының нормативлары:
18,5кә кадәр – артык ябыклык, масса дефициты;
18,5–24,9 – нормаль авырлык;
25–29,9 – артык авырлык, симезлек авыруы алдындагы хәл;
30–34,9 – 1 дәрәҗәдәге симерү авыруы;
35–39,9 – 2 дәрәҗәдәге симерү авыруы;
40тан артса – 3 дәрәҗәдәге симерү авыруы.

Киңәш

Йокысызлыктан коткара

– Мендәрне бөтнек, мәтрүшкә, абага, яран гөл, чикләвек, дәфнә яфраклары, нарат ылысы, роза таҗлары белән тутырыгыз.

– Йомшак тукымадан бәләкәй капчыктөенчек әзерләп, шуңа ике аш кашыгы төелгән колмак салырга һәм тегеп, мендәр астына куярга кирәк.

– Ылысы ванна яки тырнак гөл, мәтрүшкә, бөтнек, мелисса (һәр үлән 50 г) төнәтмәсе ваннасы керегез. 5–7 тапкыр, көнаралаш унар минут кабул итегез.

– Кич белән йоклар алдыннан 1 сәгать кала бер стакан кайнар сөт яки суга 1 кашык бал туглап эчкәндә тиз йокыга кителә.

– Төнгә каршы аякларны кайнар суда тоту да арганлыкны бетерә, нерв системасын тынычландыра.

– 1 кашык песи үләнен 1 стакан кайнар суда пешерергә, 15 минут сүрән утта кайнатырга һәм 45 минут төнәтеп, сөзәргә кирәк. Өлкәннәргә көнгә 3 тапкыр берәр аш кашыгы, балаларга берәр бал кашыгы эчәргә киңәш ителә.

Үзем сынадым



ЛИМОН БУЛЫШТЫ

Аякны көзән җыерудан түбәндәге ысулның файдасын күрә башладым. Моның өчен табан астын иртә-кич лимон согы белән уарга кирәк. Оекбашны ул аякка тулысынча сеңеп беткәч кенә киясе. Шуны 14 көн эшләргә кирәк. Суган кабыгын төнәтү дә булыша икән. Бер чәй кашыгы вакланган суган кабыгына бер стакан кайнар су салып, 10 минут төнәтәсең дә шуны йоклар алдыннан эчәсең.

Роберт ГАЛЛӘМОВ.
Әлмәт

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

МАТУРЛЫК СЕРЕ

Көннәр язга авышканда, хатын-кызларның тагын да күркәмрәк күренәселәре килә. Тик тән тиресе тәрбияләнмәгән булса, әллә нинди затлы киемнәр дә бизәми. Язга таба тирене ничек тәрбияләргә? Яшәртә торган инъекцияләрне кадатыргамы, әллә кадатмаскамы?

Әлеге һәм башка сорауларга косметолог Алинә ГАНИЕВА җавап бирде.

:: Бусагада яз, хәзер хатын-кызларга нәрсәләр эшләргә киңәш итәр идегез? Кайбер төр пилингларны нигә нәкъ менә хәзер ясатырга кирәк?

– 8–10 мартка кадәр, актив кояш нурлары төшә башлаганчы, «срединный» пилинглар ясату яхшы. Мәсәлән, Джесснер пилингы ике атнага бер ясатыла һәм тирене яңарту өчен файдалы. Ул тиренең өске катламына гына түгел, тирәнрәк үтә, аннан соң бит тиресе кубалакланып төшә һәм тире яңара. Пилингларның ел әйләнәсе ясала торганнары да бар, алар «аска» үтми, өскә генә тәэсир итә. Алары, гадәттә, 5–7 көн саен 4–8 курс итеп ясала. Ялкынсыну, яз көне пәйда булган сипкелләрдән, пигментацияләрдән миндальле пилинг бик яхшы булыша. Пилингларның очсызлары һәм кыйммәтләре бар. Очсызлысын ешрак ясарга туры килә.

:: Тирене чистарту ешлыгы турында да әйтеп үтсәгез иде.

– Һәр битлек яки пилинг алдыннан тирене чистартырга кирәк. Чистарту өч төрле була: ультратавышлы чистарту, механик, катнаш чистарту. Тиренең торышына карап, чистарту төре һәм ясату аралыгы сайлана: кемгәдер ай саен, ә кемгәдер алты айга бер чистарту да җитә. Тире күзәнәкләре (поры) киң һәм ялкынсынулар булса, ешрак чистартырга кирәк. Процедураларга йөрергә теләмәүчеләргә тирене чистарттырып, өендә үзенә туры килә торган тәрбияләү чаралары кулланырга да була.

:: Хәзер классик һәм буккаль массаж бик популяр. 40 яшьтән соң төрле инъекцияләрсез массаж белән генә битне яшәртеп буламы?

– Була, әмма үзебез теләгән нәтиҗәгә тулысынча ирешеп булмаска да мөмкин. Мин үзем буккаль массаж ясау яклы түгел. Классик массаж күбрәк «йомшарту» өчен, модельләштерү массажы битне «тарттыру» өчен ясала. Ул 50 минут дәвамында биттән тыш декольте, муен, иженче ияк өлешенә ясаудан гыйбарәт. Әлеге массаж лимфа системасы һәм кан әйләнеше өчен файдалы. Нәтиҗәсе булсын өчен атнасына 1–2 тапкыр 10–20 сеанс ясатырга кирәк. Әлбәттә, бу бик озак һәм кыйммәт чыга.

:: Бит тиресе турында ничә яшьтән кайгырта башларга кирәк?

– Тирене 14–15 яшьтән, проблемалы тире булса, 13 яшьтән тәрбияли башларга кирәк. Яшүсмер кызлар әле тирене карарга да мөмкин, ә менә яшүсмер малайларның моңа исе китми. Акне, бетчә, постакне булган очракта уларның косметологка алып килүче әниләр дә бар. Бер косметологка алып барганнан соң тирене тәрбияләү буенча күзаллау туа һәм алар үзләрен карап йөри башлыйлар. Яшүсмерләргә иң беренче чиратта тирене чистартырга һәм дөрес сайланган тәрбияләү чаралары (юыну геле, тоник, кремнар) кулланырга кирәк. Тагын шунысы мөһим: тоникларның составында спирт булмаганын сайларга кирәк.

:: Ботулинотерапия, мезотерапия, биоревитализация, контур пластикасы кебек «энәле» яшәртү утырганнан соң, аннан котылып булмый, диләр. Бу чыннан да шулаймы?

– Бу – кадатудан бит начарлана дигән сүз түгел. Җыерчыкка баткан биткә кадатып, 3–6 ай узганнан соң, тире үзенең баштагы халәтенә кайта башлый. Матур булып йөрергә күнеккәннән соң элекке рәвешләренә кайтуны кайбер хатын-кызлар кабул итә алмый. Элек яхшы иде, хәзер начаррак дип, ул аны элеккегә халәте белән түгел, ә инъекция ясаткан вакыттагы халәте белән чагыштыра. Яхшыга тиз ияләшәсең бит. Инъекцион косметология – биоревитализация һәм мезотерапия яхшы нәтиҗә бирә. Аларны ел әйләнәсе ясарга мөмкин. Ул бер кадатканнан соң ярты елга җитәргә мөмкин. Аларның чит илнеке һәм Россиянеке булганнары бар. Безнеке дә сыйфат ягыннан калышмый. Биоревитализация белән мезотерапиянең аермасы шунда: беренчесендә гиалурон кислотасының югары концентрациясе күп, лифтинг эффект бирә, дымландыра, икенчесендә гиалурон кислотасы аз микъдарда, тик файдалы витаминнар күп, ул вак җыерчыкларны бетерә, битне сафландырып, яшәртеп җибәрә. Җыерчыклардан котылу өчен ботулинотерапия ясатырга мөмкин. Мәсәлән, 20 яшьлек кызда да мимик җыерчыклар була. Бу – алардан котылу өчен менә дигән чара. Иренгә контур пластикасы җыелма эффектка да ия. Ассиметрия булганда, нечкә иренле кызларга, иренгә контур пластикасы ясатырга мөмкин. Аз гына дозада кулланганда ул иренне күпертми, ә дымландыра гына.

Алинә Ганиеваның шәхси архивыннан

:: Инъекция косметологиясе белән икенче ияктән котылып буламы?

– Инъекция липолизы (липолиптик) май катламын яндыра. Ул ярты елга бер ясала. Икенче ияктән котылу өчен липолиптик инъекция һәм массаж куллану бик яхшы нәтиҗә бирә.

:: Косметологка йөрмәүчеләрнең өендә кимендә нәрсә булырга тиеш?

– Дөрес сайланган, өйдә куллана торган тирене тәрбияләү чаралары булырга тиеш. Тире халәтенең 30–40% матурлыгын җуймавы, төрле процедуралардан соң да тиренең матур, сәламәт булып калуында өйдә кулланыла торган тәрбия чараларының әһәмияте зур. Юыну өчен гель, иртә-кич өчен дә ярый торган кремнар булырга тиеш. Кайберәүләр тоник сөртүне кирәк тапмый. Ә ул pH балансны көйли, аны иртә һәм кич сөртү гадәтен булдыру кирәк. Шулай ук җәйгә крем сайлаганда безнең җирлек өчен SPF – 20–30, җылы якларга барганда 40тан артык булганны сайларга кирәк. Күз кырыена сөртә торган крем турында да онытмагыз, аны 18 яшьтән сөртә башларга киңәш итәм. Сыворотка – яхшы концентрант, ул бик файдалы, анда актив компонентлар күп. Аны да иртә-кич сөртергә кирәк.

Укучы киңәше

12 яшьлек кызым балык исен дә, тәмен дә яратмый, шунлыктан аңа балык ашата алмый идем. Яшүсмерләр өчен аның рационда булуы аеруча мөһим бит. Ә күптән түгел бер ысул кулландым. Юылган скумбрияне тозлап, аңа борыч белән вакланган кипкән имбир, лимон согы сибеп, фольгага төреп, мичтә пешердем. Бер исе дә чыкмады, кызым, тәме дә тәмле, исе дә юк дип, яратып ашады. Балаларына балык ашата алмаучылар, сез дә шулай эшләп карагыз әле.

Альмира ГАЛИМҖАНОВА.
Казан

Үзем сынадым

ТӘРӘЗӘ ТӨБЕМ – БАКЧА

Ел саен тәрәзә төбендә кыяр үстерәм. Төрле сортларны сынап караганым бар.

Берничә ел озын булып үсә торган кытай кыярларын сынадым. «Гудвин», «Шанхайский молодец» кебек сортларның кыярлары озын булып үсә, бу сортлар яктылык җитешмәүгә талымсыз, үзлегеннән серкәләнә. Шуңа курыкмыйча чәчә, үстерә аласыз. Әмма бер кимчелеге – бер кыярын үстереп бетермичә, яңаларының үсеше туктарланып тора. Ә кыярлары шактый озын, 40 сантиметрдан арта. Быел Яңа ел каникулында 3 төп кенә гадәти партенокарпик гибрид чәчтем. «Вкус детства» сортын беренче тапкыр сынавым, яхшы үсәләр.

Кыярның чүлмәге зур булырга тиеш, бер төпкә кимендә 5 литрлы чүлмәк кирәк. Туфрак: 5 өлеш кара туфракка 1 өлеш Биогумус һәм 1әр стакан перлит һәм көл кушып ясалган. Кыяр яктылык ярата, шуңа аңа ул җитәрлек булырга тиеш. Фитолампа белән яктыртмыйча булмый, югыйсә үсенте үсә алмый, егылачак. Әле хәзер дә тәрәзә төбендә табигый кояш нурлары җитми. Кояш булмаган көннәрдә 12 сәгатькә (иртәнге 7дән кичке 7гә кадәр) фитолампа куям. Кыярга дымлы һава кирәк, көн саен пульверизатордан су бөрким, бу пәрәвез талпаны булмасын өчен дә кирәк.

Тәрәзә төбендә зур уңыш алырга өметләнмәгез. Шулай да март башында үз кыярыңны өзеп ашау бик күңелле.

Бакчачы журналист
Роза НУРГАЛИЕВА

Роза Нургалиева

Тәмле булсын!

Файдалы кәтлит

Алсу НИЗАМОВА рецепты

Кирәк: *800 г тавык фаршы, бик зур булмаган 1 баш суган, 1 кишер, 1 ташкабак, 100 г дөге, 1 йомырка, тәменчә тоз, баллы паприка, кипкән сарымсак.*

Суганны вак итеп турарга, кишерне уарга һәм икесен бергә йомшарганчы кыздырып алырга. Дөгене катырак калырлык итеп пешерергә. Ташкабакны эре угычтан уып, суын сыгарга. Аннары барлык ингредиентларны кушып яхшылап болгатырга. Кәтлитләр ясап, 180 градуслы мичкә 25–30 минутка тыгып алырга.

БАШ ТА, ТЕРӘК ТӘ БУЛСЫН

Аллаһы Тәгалә Җир йөзендә хәлифә буларак Адәм галәйһиссәламне, ягъни ир-ат кешене урнаштырган. Шул рәвешле аңа, зур дәрәҗә белән беррәттән, олы җаваплылык та биргән. Көчле зат саналган ир-атларыбыз бу дәрәҗәне бүген дә саклап кала алдымы? Гаиләләрдә ир хакы хакланамы? Малай тәрбияләгән ата-ана нинди кагыйдәләрне истә тотарга тиеш?

«Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВка шул сорау белән мөрәҗәгать иттек.

:: Алмаз хәзрәт, елның-елында шушы чорда ир хакы, ир кадере турында сөйләшәбез. Әмма быел бу сүзләр икеләтә тирән мәгънәгә ия, шулай бит?

– Әйе, соңгы арада ил-көндә барган вакыйгалар ир-ат абруен да, ир-ат кадерен дә арттырды. Адәм баласы булган әйбернең кадерен белми, аны югалткач кына аңлый бит. Гаиләбез бөтен, якыннарыбыз янәшәдә булганда, бер-беребезнең кадерен аңлап бетермибез. Ирләрен, әтиләрен махсус хәрби операциягә озатучылар бу сүзләр белән бигрәк тә килешер. Әмма Аллаһы Тәгалә безне шул рәвешле сынап карый. Адәм баласы, барыннан да бигрәк, биргән нигъмәтләрнең кадерен белмәгән, шөкер кылмаган өчен сынала. Шушы сынаулардан соң Аллаһы Тәгалә үзенең рәхмәтен бирә. Бәлкем, кеше әлеге вакыйгалардан соң тәрбияләнеп, гаиләләр ныгыр, ирләрнең кадере артыр.

:: Шулай да соңгы арада: «Хәзер чын ир-атларны бармак белән генә санарлык. Көчле зат булырга тиеш ир-атлар, киресенчә, көчсезләнә бара. Араларында тормышны хатын-кыз алып барырга тиеш дип санаучылары да шактый», – дигәнрәк фикерләр ишетергә туры килә. Бу фикер белән килешәсезме? Көчле зат саналган ир-атлар ник көчсезләнә бара?

Очрашуда укучылар: «Нинди һөнәрне сайласаң югалмыйсың?» – дип тә сораганнар. Биотехнолог, логистларга ихтыяҗ зур, дип уйлый эшмәкәр. «Кешеләр озаграк яшәячәк. Медицинада гомер озынайту өчен биотехнологлар кирәк. Ни өчен логистика? Бүген маркетплейслар, товарларны илтеп җиткерү базары үсә. Сез дә «Вайлдберриз»дан әйбер аласыздыр бит? Әйтик, нинди булса, блокнот кирәк, ди. Яхшы логист аны ике көн эчендә Түбән Камага ягулыкны, башкасын янга калдырып, кыйммәткә төшмәслек итеп тизрәк китерү җаен эзли. Логист – уникаль профессия», – ди Илнар Сираев.

Сан

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, узган ел башы белән чагыштырганда, быел авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүчеләр – **1** мең (хәзерге вакытта **41** мең кеше хезмәт куя), төзелештә – **1,2** мең (хәзер **81** мең), файдалы казылмалар чыгаруда – **1,3** мең (**33,5** мең), транспорт һәм саклауда **2** мең (**109,2** мең) кешегә арткан. Сәүдә тармагында хезмәт куючылар – **2,5** мең (**137,4** мең), мәгарифтә – **2,1** мең (**144,8** мең), электр энергиясе, газ һәм пар белән тәэмин итүдә – **1,2** мең (**32,8** мең), финанс һәм иминият өлкәсендә **800** (**27** мең) кешегә кимегән.

ФИКЕР

Александр ИБУШЕВ,
Теләче районының Шәтке мәктәбе директоры:

– Балалар һөнәр сайлый белми, дип әйтеп булмый. Әгәр малайлар әтиләре янында кайнашып үссә, алар шул һөнәрне сайларга әзер. Бер укучыбыз хуҗалыктан стипендиат булып укырга китте. 8 нче сыйныфны тәмамлаганда ук, механизатор, инженер булам, дигән иде. Бер елдан укып бетереп эшкә кайтачак. Кемдер укытучы, кемдер төзүче, спортчы булырга тели. Төрле фикердәге балалар бар. Кайберләре үз белем дәрәҗәсен белми, күп акча эшләргә тели. Әйтик, мин программист булам, диләр. Аның өчен информатиканы белү генә җитми, математика, физика да кирәк, дип аңлатабыз. Үзләре сайлаган юнәлешкә барганда, бик яхшы укыйлар. Мәктәпкә очрашуга авыл хуҗалыгы җитәкчесен чакырабыз. Хуҗалык үзенә кирәкле кадрлар буенча кызыксындыру алып барса, стипендия генә түгел, яхшы хезмәт хакы түләсә, торак белән тәэмин итсә, авылда балалар калачак.

Галина АХМЕРОВА,
«Дарвин» заманча белем бирү мөмкинлеген үстерү фонды директоры:

– Безнең илдә укучыларның 30 проценты гына белгечлеге буенча эшли. Минемчә, яшьләр вузга БДИ баллары җитә торган җиргә керә. Мәгариф үсеше фонды идеологы буларак, мин һөнәрне кызыксынудан чыгып сайларга кирәк дип саныйм. Һәм безнең барлык проектлар да шул хакта. Эшнең актуальлеге, базарда һөнәргә ихтыяҗ булу, һөнәрне әти-әниләр теләге буенча сайлау яки яшьтәшләргә ияреп укырга керү кешедән белгеч ясамый. Киресенчә, ул аның һөнәри яктан «януы»на гына китерәчәк. Әйе, яхшы акчаны теләкләреңне тормышка ашыра алган өлкәдә дә эшләп була һәм шулай кирәк тә. Әгәр һөнәр дөрес сайланмаган икән, монда куркыныч әйбер күрмим. Яңадан башларга беркайчан да соң түгел. Мәсәлән, минем «Round: хобби һәм мавыгу» платформасы өченче декреттан соң барлыкка килде. Дөнья шулкадәр тиз үзгәрә ки, һәрвакыт яңа нәрсә башларга мөмкин.

Яхшы белгечләр һәрвакыт кирәк булачак. Әгәр сезнең гаиләнең үз табибы, юристы бар икән, сезнең барысы да яхшы! Менә шуннан үлчәгез. Трендлар турында сөйләгәндә, хезмәт базарында инженерлар, авыл хуҗалыгы кадрларына ихтыяҗ бар. Техника һәм технология – дефицитта. Россиядә сәнәгатьтә эшләргә кеше юк. Ә урыннар бар, компанияләр яхшы белгечкә яхшы акча түләргә әзер.

Эмиль ГОБӘЙДУЛЛИН,
Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге генераль директоры:

– 6–7 нче сыйныфта бала кем булырга теләгәнен чамалый башларга тиеш инде. Шуңа карап, әти-әниләр өстәмә түгәрәкләр, репетиторлар сайлый. Әйтик, мәгълүмат технологияләре профиле сыйныфына барса, аңа математика, информатикадан имтихан тапшырырга кирәк. Әти-әниләр, бала белән бергә утырып, аның мөмкинлекләреннән чыгып, барысын да ныклап уйласын иде. Күбесендә әти-әни кая әйтә, бала шунда бара. Ә бит аңа гомер буе шул эштә эшләргә кирәк булачак. Киләчәктә нинди белгечлекләр популяр булуына да игътибар итегез. Кемгәдер һөнәр сайларга күбрәк вакыт кирәк. Әйтик, «Ворлдскиллс»та да мәктәптә укыганда – бер, көллияттә икенче һөнәр юнәлешендә чыгыш ясаучылар бар. Алары үзләрен шулай таба.

КАДЕРЛЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Көрәш үзебезгә кирәк

Җомга иртәсендә келәмгә чыгып, кулларына сөлге алган егетләр җиңү турында хыялланса, Татарстан Көрәш федерациясенең президиум утырышында катнашучылар милли спорт төренең киләчәге турында сөйләште. Сораулар һәм бурычлар шул ук аныслы. Әмма тормыш үзгәреп тора, яңа мәшәкатьләр чыгып тора. Көрәшне үстерергә, һич югы ничек тә булганны югалтмаска иде. Әлеге дә баягы «Казанда ниләр эшләп була?» дигән сорауга җавап эзләнде утырышта. Бу хакта башкала җитәкчеләре дәрәҗәсендә сөйләшергә килештеләр. Дөрес, аңа кадәр көрәшчеләрнең башта үзләренә бер юлдан барырга кирәк әле. Казан димәктән, биредәге Авыл хуҗалыгы институты заманында көрәшчеләр үзәге саналды. Авылдан килгән егетләр шунда осталыгын нығытты. Уку йортыннан бик күп батырлар үсеп чыкты. Хәзер ул аграр университет дип йөртелә. Аның каравы сөлге тота белгән егетләргә шөгыльләнергә урын юк икән. Чистайдагы авыл хуҗалыгы техникумын да искә алдылар. Мактап түгел. Сөйләшүнең нәтиҗәсе булмый калмас дип өметләник.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Көрәш федерациясе җитәкчесе Марат Әхмәтов көрәшнең генә түгел, көрәшчеләрнең киләчәге турында да уйланырга киңәш итте. Келәмнән киткәч югалып калмасын, тормышта үзләренә юл тапсын өчен, аларның бер-берсенә ярдәм итүләре кирәк. Әлбәттә, мондый эшне документка кертеп тә, кагыйдәләрен дә язып булмый. Аның каравы көрәшчеләрнең абруен күтәрәчәк, яшьләрдә ышанычны арттырачак. Бу эш матур гадәткә әверелеп китсә, көрәшнең районнардагы хәле дә яхшырыр иде. Кыскасы, көрәш иң элек үзебезгә кирәк.

Рәхмәт сүзе

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә көрәш буенча 60 нчы юбилей бәйгесен оештыруда төп эшне башкарган Татарстанның Көрәш федерациясенә, Спорт министрлыгына, турнирның ачылу тантанасын әзерләүдә зур ярдәм күрсәткән өчен Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры коллективына зур рәхмәтен җиткерә.

Икесе – ике якка

Мәгънәле ачылу тантанасы белән башланган турнирның беренче көне сәгать кичке сигез тулып киткәч кенә тәмамланды. 60 нчы бәйгенең батырларын ачыклау өчен, егетләр икенче көнне иртәнге тугызда янә келәмгә чыкты. Тамашачы да игътибарсыз калдырмады. Соңгы елларда «Ак барс» көрәш сараенда иң күп халык җыелган бәйгеләрнең берсе булды Муса Җәлил турнирының быелгысы. Көрәшчеләрне бер яктан тамашачы да кыздырса, ярыш нәтиҗәсе буенча Россия чемпионатында катнашачак команда җыелу да йогынты ясамый калмады.

Көз көне 60 килолы егетләр арасында Татарстан чемпионы булып, соңрак Россия батыры булып танылган Алексей Абрамов, ниһаять, Муса Җәлил бәйгесенең финалына да барып җитте. Лаеш өчен бил алышучы 23 яшьлек егет узган ел өченче урын белән канәгатьләнгән иде. Быел хәлиткеч алышта Алексейга үзенең командадагы дусты белән бил алышырга туры килде. Тумышы белән Азнакайдан булган 19 яшьлек Илфат Миңнегалиев тырышты, әмма тәҗрибәле көндәшенә каршы тора алмады.

65 килолылар бәйгесен икенче ел рәттән 25 яшьлек Илнар Закиров отты. Алексей Абрамов белән икесе дә Алексеевск егетләре алар, тренерлары да бер үк. Тик Абрамов Казанга якынайса, Закиров кире якка китеп, Чистай өчен бил алыша. Финалда ул Әлкидән Илназ Хәмидуллинны отты һәм газетабыз бәйгесендәге җиңүләрен өчкә җиткерде. Бу гына түгел. Бәйге ахырында Илнар танылган пәһлеван Ильяс Галимов исемендәге махсус премиягә дә ия булды. Билгеле булганча, «Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Көрәш федерациясенең уртак бүләге финалда иң яхшы алым күрсәткән егеткә тапшырыла.

5 ел көтелгән җиңү

2018 елда Муса Җәлил бәйгесендә беренче җиңүен яулаганда Алабуга егете Ислам Фәлаховка нибары 20 яшь иде. Икенчесен 5 ел көтәргә насыйп булган икән көрәшчегә. Ул арада имгәнеп, келәмгә чыга алмаган вакытлары да була. Әмма сабырлыкның ни икәнен яхшы белгән Ислам хаҗи. Быел 70 килолы егетләр финалында ул Чаллыдан Айназ Тимеров белән очрашты. Айназ ике яшькә өлкәнрәк, әмма Исламда тәҗрибә күбрәк. Шуның ярдәмендә ул көндәшен өч кисәтү алырга мәҗбүр итте.

Лаеш өчен чыгыш ясаучы Динар Кәримуллинда да тәҗрибә җитәрлек. Халыкара класслы спорт остасы исе-

БЫЕЛГЫ ҖИҢҮЧЕЛӘР

Алексей АБРАМОВ (60 кг):
– Көндәшемнең көрәшеннән ни көтәсен белә идем. Бергә әзерләнәбез бит. Ул да яхшы нәтиҗә күрсәтте дип саныйм. Финалга кадәр җитте. Мин көрәшеп җиңгәннән соң гел сальто ясыйм. Шатлыгымны башкача күрсәтә белмим. Үзеннән-үзе шулай килеп чыга инде ул.



Илнар ЗАКИРОВ (65 кг):
– Көрәшкәндә үз-үземне искиткеч хис иттем! Келәмгә чыккач, өстәмә көч кереп киткәндәй булды. Проблемалар булмаска тиеш иде. Келәмгә чыккач, бернинди имгәнүләр, җәрәхәтләр турында уйламыйсың, аларны сизмисең дә. Алар комачау итми. Барлык уйлар җиңү турында гына. Без шуның өчен келәмгә чыгабыз да инде. Көндәшемнең көрәшүен дә яхшы бәялим. Яшьләр артыбыздан килә. Тагын да күбрәк шөгыльләнергә кирәк дигән сүз! Ильяс Галимов исемендәге махсус премиягә дә бик куандым. Бу көтелмәгән куанычлы мизгел булды! Миңа Ильяс Галимов турында күп ишетергә туры килде. Көрәш тарихында аның үз исеме бар. Бик горурланам.

Ислам ФӘЛАХОВ (70 кг):
– Җәлил турнирында җиңү генә түгел, Россия чемпионатына юллама да оттым! Дөресен әйтим: авыр булды. Шактый тир түгәргә туры килде. Егетләр әзерлекле, аларга афәрин! Көндәшлек чынлап та бик зур. Мин үземә: «Үлсәм үләм, әмма җиңәм!» – дидем. Россия беренчелегенә бик барасы килә. Шуңа да тырыштым. Шушы ярышларга чыгу өчен әзерләнәбез бит инде. Безнең күнекмәләрнең мәгънәсе дә – шул ярышлар. Шуңа күрә җиңәргә дип чыгабыз.



Динар КӘРИМУЛЛИН (75 кг):
– Финалда җиңел булмады. Авыр хәлдән чыгарга туры килде. 2:0 исәбе белән оттырып бара идем. Ахыргы бер минутта көндәшне куып тотып, җиңеп чыктым. Көндәшем – Илназ Рамазанов та бик көчле иде. Аңа рәхмәт! Нык көрәште. Муса Җәлил турнирына иң көчле көрәшчеләр җыела. Бу ярышны өченче мәртәбә отам инде, әмма ул җиңүләрнең берсе дә җиңел генә бирелмәде. Авырлыгын үзем генә беләм. Җиңү рецепты шул инде: тырышлык һәм күнекмәләр. Җитди әзерлек булырга тиеш. Мин 6 яшьтән бирле көрәшәм. Җиңү өчен максат кирәк. Җиңелдем дип, баш ияргә кирәкми! Җиңелгәнем дә бар. Шулардан гыйбрәт алып, үзеңне яңа дәрәҗәгә үстерергә кирәк. Җиңүләр җиңелүләр аша килә.

Эмиль МАВЛИН (80 кг):
– Көрәшчеләрнең барысы да бик көчле. Матур көрәш күрсәтә алдык дип уйлыйм. Миңа хәзер 21 яшь, 6 яшьтән бирле көрәшәм. 8 яшьтән җитди ярышларда катнаша башладым. Муса Җәлил исемендәге турнирда өченче мәртәбә катнашам. Беренче тапкыр җиңүем! Уңышка ирешүнең сере – дөрес итеп шөгыльләнүдә. Режим, дисциплина дигәне дә булырга тиеш көрәшченең. Остазларыма рәхмәт. Бу җиңүдә аларның өлеше бик зур. Келәмгә чыкканчы, көндәшемнең көрәшен күзәтәм, нинди алымнар кулланыуын өйрәнәм. Тренер белән сөйләшеп, тактика уйлап, көрәшкә чыгабыз. Келәмгә дога укып чыгам. Минем кумирым бар, ул да булса – Криштиану Роналду. Җиңүче, мин дә аның кебек җиңүемне билгеләп үтәм, аның алымын кабатлыйм. Аерым рәхмәтемне тамашачыларга һәм әтиемә җиткерәм. Әти булмаса, мин монда басып тормас идем.

БАТЫРЛАР

мен йөртә ул. Әмма Илназ Рамазановның да җиңүләре аз түгел. Тукай районының мактаулы кешесе исеменә ия булган 22 яшьлек егет 75 килолы көрәшчеләр финалында көндәшенә ахырга кадәр өстенлек бирмәде. Ә санаулы секундлар калгач, бер ялгышлык аркасында оттырырга мәҗбүр булды. Дөрес, узган ел өченче булса, быел икенчегә күтәрелде. Ә Кәримуллин бәйгедәге өченче урынына ирешә.

Динар – тумышы белән Теләчедән. Ә бу районнан Эмиль Мавлин – аның шәкерте. Нәкъ менә бу егет 80 килолылар ярышында җиңүче булып танылды. Финалда ул үзе белән бер командада бил алышкан Артур Зөлкарнәевтән өстен чыкты. Артур – Башкортстаннан. Шуңа күрә бәйгедә җиңелгәненә артык борчылмады дип уйларга җирлек бар. Чөнки Россия чемпионатында барыбер үз республикасының данын яклаячак.

Ренас тәнәфескә чыкмый

Көрәш буенча Россиянең атказанган спорт остасы, Муса Җәлил бәйгесенең җиде тапкыр җиңүчесе. Бу – Теләчедән Ренас Кәлимуллин. 1 разрядлы спортчы, бәйгенең бер тапкыр җиңүчесе. Ә бу – Чаллыдан Рөстәм Сәлахов. 85 килолылар арасында кем көчлерәк? Җавап дөрес. Әмма моны раслау Ренаска бер дә җиңел булмады. Хәзер ул – сигез тапкыр җиңүче. 2016 елдан бирле рәттән отып бара. 2002–2010 елларда шундый ук нәтиҗәләр белән Илнар Әхмәтҗанов уңышка ирешкән иде. Кыскасы, Кәлимуллинның яңа максаты билгеле. Дөрес, Сәлаховларның кечесе һәм башкаларның да үз максатлары бар.

Лаештан 24 яшьлек Раил Сәлахетдинов дүртенче җиңүен яулады. 90 килолы егетләр арасында бил алышучы көрәшче ярымфиналда тәҗрибәле Илмир Төхвәтуллинны отты, финалда Әлмәттән Айрат Сәмигуллиннан өстен чыкты. Раил – яшь, уҗат, тамашачыны битараф калдырмас өчен ни эшләргә кирәклеген чамалый. Калганын киләчәк күрсәтер.

100 килолылар бәйгесендә тамашачыга суперфинал өммәтендәге очрашу күрергә насыйп булды. Келәмгә Чаллыдан Эльдар Хәмитов белән Казаннан Булат Мусин чыкты. Көрәш дөньясында исемнәре иң популяр булган егетләр. Рәсемнәрен шәһәр урамнарына куеп, горурланырлык егетләр. Газетабызга исә берсенең генә рәсемен куябыз. Булат Эльдарны 6:0 исәбе белән отып, бәйгедә бишенче җиңүен яулады.

Раил Айдар белән янәшә

Тәүге тапкыр 115 килолы егетләр ярышын күрде турнирга килгән тамашачы. Фаворит алдан ук билгеле иде. Теләче батыры Раил Нургалиев барысының да өметен аклады. Финалда ул Башкортстаннан килеп, Чистай өчен бил алышучы Айнур Сыртаевны отты. Хәзер Раилнең 10 җиңүе бар һәм ул Балтачтан Айдар Хәйретдинов белән тигезләште. Турнир рекордчысы Айрат Гыйлаевны куып тоту өчен тагын ике җиңү кирәк әле. Булдыра алырмы?

Хәлил ШӘЙХЕТДИНОВ, Татарстан спорт министрының беренче урынбасары, Муса Җәлил бәйгесенең 1991 елгы җиңүчесе:
– 60 нчы тапкыр үткәрелә торган бу ярыш – бик дәрәҗәле, бик мактаулы. 350ләп көрәшче осталык күрсәтте. Көрәш бик матур, кискен барды. Шунысына сөендек: тамашачылар күп. һәркайсының яраткан көрәшчесе бар. Шулар өчен җан атып утырдылар. һәр үлчәү категориясендә беренче урынны яуларга лаеклы бишәр-алтышар егетебез бар. Шушы көрәш нәтиҗәләре буенча без Татарстан җыелма командасын тупладык. Апрельдә Россия чемпионаты көтә. Анда җиңүләр насыйп булса, дөнья чемпионатында да ярышачаклар. Чаллы, Теләче, Әлмәт, Лаеш командалары бик матур көрәш күрсәтте. Болар барысы да – безнең байлыгыбыз. Шушындый көчле ирегетләребез үрнәк булып тора.

130 килолылар арасында фаворитлар саналган Радик Сәлахов белән Муса Галләмов финалда ук очрашты. Радик келәмгә «Әлмәт» дип язылган футболка киеп чыкса да, Муса кебек ук Лаеш өчен бил алыша. Шуңа күрә көрәшеп тормадылар. Сәлахов беренче алымы белән үк Галләмовны чистага салды. «Билгә төшердең», – дип зарланып алды Муса. Радик исә финалда Казан егете Лениз Абдуллинны отты. 39 яшьлек Лениз – безнең бәйгенең 4 тапкыр җиңүчесе. Тәүге уңышына әле 2009 елда ук ирешкән булган. Хәзер Радикның да 4 җиңүе бар.

Иң авыр егетләр ярышын кем отасы төп алышлар башланганчы ук аңлашылды. Чаллыдан Ранис Гыйлаҗетдиновның Ульян пәһлеваны Сергей Павликны берничә мәртәбә күтәреп салуын күргән тамашачы битараф калмады: егеткә алкышны кызганмадылар. Дөрес, Павлик булган җирдә төрле сүзләр дә йөри. Ә Ранисның – үз юлы. Финалда Арчадан Альберт Ситдыйковны отып, иң авырлар арасында рәттән икенче җиңүен яулады.

Лаешмы, Чаллымы? Күчмә Кубокның кемгә эләгәсе ахырга кадәр билгеле түгел иде. Әмма Лаеш егетләре нибары 2,5 балл аерма белән булса да, барыбер үз дигәннәренә ирешә алдылар. Район тарихында тәүге тапкыр! Иң соңгаен кешеләрнең берсе Азат Нурмөхәммәтов булды. Танылган көрәшче, хәзер районда көрәш өчен җаваплы төп кеше. «Аллаһка шөкер, менә бит, ниһаять, кубоклы булдык! Хис-кичерешләр турында әйтеп аңлатырлык түгел, – диде ул. – Тулы куәткә Россия ярышларына әзерләнәсе хәзер. Егетләргә афәрин! Бу җиңү һәм бу көрәш безнең өчен бик кадерле».

Илнар ХӘСНУЛЛИН,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БӘЙГЕНЕҢ ФИНАЛ ЯРЫШЛАРЫННАН ВИДЕОМИЗГЕЛЛӘР

БЫЕЛГЫ ҖИҢҮЧЕЛӘР

Ренас КӘЛИМУЛЛИН (85 кг):
– Көрәш киеренке булды. Минем әле реванш та аласым бар иде бит. Әмма көрәш барышын контрольдә тоттым. Минем тәҗрибәм зур. Раил Нургалиев артыннан куам. Сигезенче җиңүдә генә тукталасы килми. Юбилей турнирында җиңү, чынлап та, авыррак булды. Әле көндәшем дә яңа бит. Яшьләр артыбыздан басырып килә. Юк, дөресрәге, басарга тырышалар, дип әйтик. Сер бирмибез әле!



Раил СӘЛАХЕТДИНОВ (90 кг):
– Көрәш авыр булды. Турнирның беренче көнендә Илнар Галимовны җиңдем. Бүген исә Айрат Сәмигуллин белән Илмир Төхвәтуллинга туры килдем. Минем төп көндәшләрем шулар иде. Муса Җәлил турнирындагы бишенче финал, дүртенче җиңүем бу. Бүген җиңгәч, тегеләре онытыла да кебек. Һәр яңа җиңү яңа азарт өсти. Тренерга, тамашачыга, әти-әнигә рәхмәт!

Булат МУСИН (100 кг):
– Ярышны әти, сеңлем трибунадан күзәтте. Әтиемнең бер генә ярышны да калдырганы юк. Хатыным – эштә (*көлә*). Хатынга ашаткан өчен рәхмәт әйтәм! Авырлык җыйдым бугай. Көрәшче хатыны план буенча ашата ул. Серләрне чишеп тормыйм (*көлә*). Өйләнгәнче дә яхшы көрәшә идем мин, өйләнгәч тә яхшы көрәшәм! Тренерга, абыйга рәхмәт! Юбилей турнирында бишенче җиңүемне яуладым. Шунысы да бар: беренче әйләнештә көрәш авыррак барды. Мин әле «мине тамашачы ярата» дип уйлыйм идем. Әмма шул мәлдә башкача мөнәсәбәт сиздем. Җанатарлар миңа каршы булды төсле. Аз гына психологик басым булды инде. Бер дә көтмәгән идем.

Раил НУРГАЛИЕВ (115 кг):
– 115 кг – яңа категория. Күптән кирәк иде ул. Минем авырлыгым – 112 кг. Миңа бик уңайлы булды. Оештыручыларга мондый категория керткәннәре өчен рәхмәт! Миңа калса, ул барысы өчен дә уңайлы үлчәү.
Быелгы җиңүемне гаиләмә багышладым. Алар туры эфирдан күзәтте ярышны. Батыр булу өчен нишләргәме? Ит, бәрәңге ашарга (*көлә*). Алай гына түгел, әлбәттә. Шөгыльләнергә кирәк! Әйбәт тренер кирәк, аны тыңларга кирәк. Шул чакта гына барысы да була. Куып тотарга җыенучылар бардыр. Әмма мин үземне беләм, шөкер.

Радик СӘЛАХОВ (130 кг):
– Муса Җәлил турнирын беркайчан да җиңел генә отам димә. Шуңа күрә тренерлар белән шактый шөгыльләнергә туры килде. Мин 90 кг үлчәүдә ярыша идем бит. Хәзер 130 килолылар арасында. Бераз гына үзгәрергә туры килде, дисәм була. Бу – минем дүртенче җиңүем. Алга таба тагын да яңа үрләр көтсен. Быелгы җиңүемне әтиемә багышлыйм!

Ранис ГЫЙЛАҖЕТДИНОВ (130+ кг):
– Җиңү авыр бирелде. Бик нык әзерләндек. Ярыш белән ярыш арасы да кыска булды бит. Безгә бу турнирга әзерләнү өчен шактый тырышырга, күп көч куярга туры килде. Көндәшләрем дә әзерлекле. Барысы да көчле! Бу җиңүемне әти-әниемә, яраткан кызыма һәм якыннарыма багышлыйм.

60 кило
I урын – Алексей Абрамов (Лаеш)
II урын – Илфат Миңнегалиев (Лаеш)
III урын – Ришат Исхаков (Чаллы), Дмитрий Гайниев (Әлмәт)
65 кило:
I урын – Илнар Закиров (Чистай)
II урын – Илназ Хәмидуллин (Әлки)
III урын – Илназ Димиев (Лаеш), Илһам Гайфетдинов (Мамадыш)
70 кило
I урын – Ислам Фәлахов (Алабуга)
II урын – Айназ Тимеров (Чаллы)
III урын – Рафаэль Билданов (Әлмәт), Айнур Мирзаянов (Чаллы)
75 кило
I урын – Динар Кәримуллин (Лаеш)
II урын – Илназ Рамазанов (Тукай)
III урын – Булат Гадершин (Чистай), Ринат Мингалиев (Чаллы)
80 кило
I урын – Эмиль Мавлин (Теләче)
II урын – Артур Зөлкарнәев (Теләче)
III урын – Айзат Гәрәев (Балтач), Ленар Садыйков (Чаллы)
85 кило
I урын – Ренас Кәлимуллин (Теләче)
II урын – Рөстәм Сәлахов (Чаллы)
III урын – Азат Гәбдрәшитов (Чаллы), Виталий Колесников (Чаллы)
90 кило
I урын – Раил Сәлахетдинов (Лаеш)
II урын – Айрат Сәмигуллин (Әлмәт)
III урын – Руслан Зыятдинов (Питрәч), Илмир Төхвәтуллин (Лаеш)
100 кило
I урын – Булат Мусин (Казан)
II урын – Эльдар Хәмитов (Чаллы)
III урын – Руслан Шәнгәрәев (Чаллы), Айгиз Зәйнетдинов (Теләче)
115 кило
I урын – Раил Нургалиев (Теләче)
II урын – Айнур Сыртаев (Чистай)
III урын – Дилүс Закиров (Саба), Рифат Ахунҗанов (Саба)
130 кило
I урын – Радик Сәлахов (Лаеш)
II урын – Лениз Абдуллин (Казан, Вахитов)
III урын – Муса Галләмов (Лаеш), Турал Азимов (Чистай)
130+ кило
I урын – Ранис Гыйлаҗетдинов (Чаллы)
II урын – Альберт Ситдыйков (Арча)
III урын – Рөстәм Бәдретдинов (Чаллы), Фирдүс Зәйнуллин (Казан, Яңа Савин)

Командалар беренчелеге
1. Лаеш
2. Чаллы (Комсомол)
3. Теләче
4. Әлмәт
5. Чаллы (Автозавод)
6. Арча
7. Чистай
8. Кукмара
9. Казан, Яңа Савин
10. Балтач

ӘНВӘР НУРГАЛИЕВ:

«ЧЫН ИР-АТ АРМИЯДӘ ТӘРБИЯЛӘНӘ»

Ир-егеткә хас сыйфатлар, хатын-кыз тамашачы җырчысы булу кыенлыклары һәм өстенлекләре, тормыштагы казанышлар һәм үкенечләр турында Башкортстанның халык, Татарстанның атказанган артисты Әнвәр НУРГАЛИЕВ белән сөйләштек.



:: Ир-атка хас төп өч сыйфат нинди?

– Ныклык, намуслы булу, тәртип. Бу сыйфатларны егетләрдә армия тәрбияли. Чөнки армия – үсмер чак белән ир-егет арасындагы чик ул. Хәзер күпчелек яшьләрдә әнә шушы күчеш чоры булмый. Шуңа күрә аларга мөстәкыйль тормышка күчү авыргарак бирелә.

:: Элек армиядә булмаган егетне егеткә дә санамаганнар. Аннары армиядән котылып кала алганнар егет булып йөрде. Хәзер дөнья кай якка үзгәрде?

– Хәзер вазгыять элеккеге эзенә кайта. Заман үзгәрде, яклаучы, сакчы дигән төшенчәләр алгы планга чыкты. Юкса ир кешедә гаиләне яклаучы дигән нәрсә дә юкка чыга язды. Алгы планга хатын-кыз чыкты. Ул – тормышны алып баручы да, дөнья йөген тартучы да, табучы да, яклаучы да. Алай булырга тиеш түгел.

:: Мобилизация гаиләгезгә кагылдымы?

– Апамның улы хәрби юлны сайлаган иде. Ул инде 20 ел хәрби хезмәттә. Сүз уңаеннан: мин «контрактник» дигән сүзне яратмыйм. Хәрби ул – хәрби инде. «Контракт» сүзе хәрбинең сыйфатын төшерә кебек. Энемнең махсус операциядә катнашуына тиздән бер ел була. Әлбәттә, безнең гаиләгә дә кагылды, башка гаиләләргә дә. Нишлисең бит. Борчылып та, өметләнеп тә көтәбез.

:: Син ул хакта махсус җыр да иҗат итмең бугай.

– Марат Кәбиров сүзләренә Айдар Тимербаев иҗат иткән «Озату» җырын күпләр мобилизациягә багышланган дип кабул итте. Әмма анда төп фикер: авыр вакытта кешеләрнең мәхәббәт хисләренең сыналуы. Чыннан да сыналыр чакта яшибез бит. Элек без бүгенге көнне, шушы көндәге һәр мизгелне, бер-беренңе кадерләргә кирәклекне аңламагангбыз. Хисләр вакланган, юктан тавыш чыккан, дигәндәй. Ил белән авырлык күтәргәндә кыйммәтләр дә үзгәрә. Мобилизация иргә – хатынны, балаларны кадерләргә, хатынга ирне хакларга кирәклекне күрсәтте. Боларны матур сүз дип кабул итмәгез, үзем кичергәнне әйтәм. Мәсәлән, апамның улы – энекәшем белән тыныч вакытта сирәк сөйләшә идек. Язышу, шалтыратышу юк иде диярлек. Махсус операциягә китәсен белгәч, иң беренче үзем шалтыраттым. Ул да, абый, мин үзем дә сиңа шалтыратырга уйлаган идем, ди. Үзеннән-үзе якынайдык. Мин аның һәр адымын белергә тырышам. Кайтса, каршы алам, кирәк әйберләрен төяп җибәрәм. Беренче ялына кайтканда зур колонна ясап озаттык. Шунда да кешеләр бик күп начар сүзләр яздылар. Кеше нәрсә уйлыйсы килсә, шуны уйласын, әмма энекәш миңа кадерле һәм мин аңа хәлемнән килгәнчә ярдәм итәчәкмен. Дөрес, ул бер нәрсә сөйләми. Әмма күп нәрсәне интонациясеннән дә аңлап була. Мобилизациягә эләккән башка кешеләр өчен дә борчылам. Алар миңа барысы да энекәшем кебек. Егетләрнең асыллары китте, әмма күбесе ныгып өлгермәде. Безнең Рөстәм ул яктан – чын хәрби. Минем аңа, әйдә кайтарырга тырышып карыйк, дип тә әйткәнем булды. Хәтта тыңлап та тормады. Бу темага башка сөйләшмибез, диде. Шундый чын хәрбиләрдә бөтен өмет.

:: Үзеңне хатын-кызлар җырчысы дип әйтсәләр, кимсетмиме?

– Юк, әлбәттә! Җыр бит ул хисләрне уята, ниндидер хатирәләрне искә төшерә. Ә хатын-кыз ирләргә караганда хисчәнрәк, шуңа күрә музыка да аларга күбрәк якынрактыр. Аннан соң ирләр яшьтән үк хатын-кыз игътибарын җәлеп итәргә тырыша: ниндидер гамәлләр кыла, җырлый, ниһаять! Без гомер-гомергә гүзәл затның игътибарын яуларга тырышабыз. Дөрес, монда чикләрне узмаска кирәк барыбер. Әйтик, хатын-кыз игътибары ир затына комачауламаса да, аны өйдә көткән хатынына ошап бетмәскә мөмкин. Димәк, син хәләлеңә тагын да игътибарлырак булырга тиеш.

Мин бергә эшләгән ирле-бичәләрне гомер-гомергә аңлый алмадым. Ник дигәндә, берең ашатырга, берең гаиләне карарга тиеш. Үземнең гаиләдән чыгып әйтәм: мин – табучы-юнәтүче, хатыным өйдәге тәртип өчен җаваплы булды, балаларны тәрбияләде. Аңлыйм, аңа читен булгандыр, төрле сүзләр дә җиткергәннәрдер. Әле дә сүзләр килеп ирешә дип беләм. Монда инде гаилә тынычлыгы хатын-кыздан тора. Я иренә ышана ул, я читтән кергән сүзгә. Ә төп җаваплылык – ирдә. Чөнки ул гаиләсе өчен калкан булырга тиеш.

:: Татар эстрадасының төп үзенчәлеге нәрсәдә? Ул нинди сыйфатларны ярата, кайсыларын яратмый?

– Кемгәдер сәхнәдә сүгенеп җибәрсә дә килешә, кемдер ялгыш бер сүз ычкындырса да, аны гафу итмәскә мөмкиннәр. Бездә сәхнәгә нинди образ белән килеп керәсең, ахыргача шулай барырга кирәк. Әйтик, менә миңа җиңелчә генә тәртипсезлек тә гафу ителми. Әнвәр акылсыз икән, начар икән, дип шундук «элеп» алалар. Димәк, миңа кысалардан чыгарга ярамый. Миңа хайп та килешми. Хәтта комментарийларга усалрак җавап бирергә дә ярамый. Ә кемгәдер ул гафу ителә. Димәк, минем тамашачым консервативрак. Гомумән, татар эстрадасы тамашачысы консервативрак дип әйтергә була. Шуңа күрә эстрада да ниндидер бер кысада тора. Мин моны начар дип әйтмим, бәлки, ул яхшырактыр да әле. Мәскәү белән чагыштырсак инде.

:: Репертуар яшь белән бергә үзгәрәме?

– Репертуардан бигрәк, аңа салынган фикер (посыл) үзгәрә. Бер үк җырны әллә ничә төрле башкарып була. Тормыш тәҗрибәсе арткан саен, сүзләргә икенчерәк мәгънә салырга мөмкин. Әйтик, «Җылы сүзләр» җырын төрле кеше төрлечә кабул итә. Мин аны әни вафатыннан соң яздым. Безгә төрле сүзләр ишеттерделәр, хурлаучылар, чир таратучылар, дип гаепләүчеләр дә булды. Шуннан соң: «Сезнең бер дә җылы сүзегез юкмыни соң?» – дип җырладым мин аны. Кайвакыт исә елмаеп, җиңелчә генә башкарам. Концерт белән концерт та аерылырга мөмкин. Казанда куйган беренче концертымда күбрәк хисләр өстенлек алган булса, хәзер инде дөньяга караш та, күңел халәте дә икенче.

:: Булды, җитәр, эстрададан китәм, дип әйтәсе килгән чаклар буламы?

– 15 ел элек шундый халәтне кичердем. «Арыдым», – дип зарлана идем. «Миннән булмый», – дип әйтә идем. Пандемия килеп чыкты да, бөтен нәрсә туктап калды. Зарланырга ярамый, шөкер итәргә кирәк икән. Ходай барысын тигезли. Хәзер күбрәк өйдә буласым килә. Әлбәттә, концертлар да куясы килә, мин аннан башка яши алмыйм инде, әмма якынныарыма күбрәк вакыт калдырасым килә. Үз юлымны тапканмын икән, монда хатынымның да өлеше бик зур. Ул миңа ышанды һәм көч биреп торды.

:: Ир-ат җырлап кына тормыш алып бара алмыйдыр инде ул, тагын нинди һөнәр-шөгыльләрең бар?

– Эстрадага кадәр төзелеш бизнесында идем, шул өлкәдән калган шөгыльләрем бар. Төзелештән кергән акчамны «Барсмедиа»га салып, җырымны раскруткага биргән идем. Хәзер башка шөгыльләр үзләштерергә вакытым да юк инде. Җыр юнәлешендә эшлим, өйрәнәм, яхшы җиһазлар алам. Тамашачының төп таләбе – сыйфат. Ул шулай булырга тиеш тә.

:: Соңгы елларда сиңа зур сынаулар үтәргә туры килде. Ковид вакытында әниең бакыйлыкка күчте, аннан әтиең... Авыр чакта таянычың кем яки нәрсә булды?

– Гаиләм терәк булды. Бик авыр сынау булды ул, иҗатым да туктап калды, бернәрсәгә дә күңел үсмәде. Чөнки тормыш көйләнеп, инде үз тамашачым барлыкка килгәндә һәм халыкка таныганда, алар бер-бер артлы китеп бардылар. Күңел төшенкелеге биләп алды. Мин ул халәттән хатыныма таянып чыктым.

> Хәзер әти-әнигә күбрәк игътибар бирәсе калган икән дип үкенәм. Игътибар бирдем, ләкин җитәрлек булмады кебек. Кайткач, әти-әни белән күбрәк сөйләшәсе калган икән, дим... Авылга сагынып кайтам, күчтәнәчләрне тапшырам, әниең тәмле коймаклары белән чәй эчәм дә ихатага эшләргә чыгып китәм. Һәр кайткан саен шулай. Их, сөйләшәсе иде хәзер үзләре белән, янымда юк. «Яратам» дип әйтмәгәнгә үкенәм. Мин беркайчан да әнигә «яратам» дип әйтә алмадым. Кирәк булгандыр. Өлкәннәр аны барыбер көтә.

:: Тормышыңдагы иң зур казанышың нинди?

– Хыялымны тормышка ашыруым. Мәскәү, Казанда концертлар куярмын дип күз алдына да китерми идем. Әтием – көтүче, әнием гади кеше иде. Авылда бит халык төрле катлауларга бүленгән. Башта – бригадир, аннары – сатучы, укытучылар килә. Аннары машина йөртүчеләр абруйда. Алардан соң гына – көтүчеләр. Мине бәләкәй чакта букәнгә бастырып җырлаталар иде. Шунда, фамилияңне күтәрерсең әле син, дип юраучылар булды. Юраганнары юш килде.

:: Халык белмәгән нинди талантың бар?

– Талант түгел инде ул, шөгыльләрем бар. Бакчачылык белән кызыксынып киттем. Кая барсам да, тарихи биналар карарга яратам. Элеккеге җиһазлар, төрле эшләнмәләр туплый башладым. Ихатамда бер милли почмак оештырасым килә. Анда әниемнең орчыклары, күчагасы, табагачы, җилпучы, суккан паласлары бар.

Соңгы вакытта юкка чыгып барган авылларны барлый башладым. Бу җәһәттә Хәния Фәрхи, Хәмдүнә Тимергалиева туган авылларны барып күрәсем килә. Соңгы вакытта Хәмдүнә апа онытылып бара шикелле. Ул бит – феноменаль җырчы. Нинди тавыш, нинди энергетика иде аңарда. Мин Хәмдүнә апаның «Җырчы сагышы» дигән җырын шаккатып тыңлаган идем. Ул бит үзе бер чор! Телефонымда Хәния апа, Хәмдүнә апаларның язмалары саклана, кайчак кабызып, тыңлап алам. Моңсу булып китә.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЯМАН ЧИРНЕ ҖИҢГӘН АЛИЯ:

«МИНЕ КЫЗГАНМАСЫННАР»

«Көчле булырга! Ничек тә яшәргә кирәк. Өйдә ике кечкенә улым бар бит!» Кулына куркыныч авыру турында язу тоттыргач, 33 яшьлек Алиянең уе әнә шул була. 2021 елда табиблар аңарда яман шеш табалар.

– Моннан ике ел элек бар дөньяның асты өскә килде, – дип сөйли 33 яшьлек Алия Әсхәдуллина. – Декрет ялына кадәр балалар бакчасында эшләгән идем. Елдан соң төзелеш фирмасына эшкә чыгарга булдым. Тик анда бары 3 ай тирәсе генә эшләп калдым. 2021 елның май аенда авырып киттем. Ул көнне әле дә хәтерлим. Йокыдан торгач, юынып аласы иттем. Душка кердем. Култык астында шеш барлыгын сиздем. Кечкенә түгел иде ул! Моңа кадәр ничек сизми йөргәнмен!

Алияне карый башлагач, УЗИ ясаучы табибның да йөзе үзгәреп китә. Куркытмаска тырышса да, онкологка юллама бирүеннән күп нәрсә аңлашыла инде. Алия машинасына чыга да үксеп-үксеп озак итеп елый. Шушы елавы беренче һәм соңгысы була да инде. Башка ул яшь түкми.

– Эшне озакка сузмадым. Икенче көнне иртәнге алтыда ук без онколог ишеге төбендә идек инде. Табиб тагын анализлар бирергә кушып җибәрде. Атнадан артык биопсия анализын көттем. Шул вакытта инде мин үземне нәрсә көткәнен бераз чамалый башлаган идем. Әмма, ни генә булса да, җиңеп чыгарга вәгъдә бирдем. Үзем дә кызганмыйм, башкалар да кызганмасын. Әле бит минем ике улымны өйләндерәсем дә бар, – ди Алия. – Дөрес, сөйләгәндә генә шулай гади тоела ул. Мин өметләнеп килгән табибым исә күп сүзле булып чыкмады: «Хастаханәгә ятасыз, анда аңлатырлар, әлегә минем эш сәгатем бетте».

Берәү булса, мин беттем, дияр иде. Алия алай эшләми. Ул көчле булырга тырыша. Өйдәге 4 һәм 6 яшьлек сабыйларын уйлап, үзендә яшәр көч эзли. Шешне алдырып ташлаганнан соң да, әле тагын көрәшергә туры киләсен белә.

– Бер дигән табибка туры килдем. Альберт Гыйимранов белән сөйләшүдән соң мин бөтенләй тынычландым. Ышанычлы кулларда икәнемне аңладым. Операциядән соң өйгә кайтканда, биопсиянең тулы нәтиҗәсе килде. Яман шешнең икенче генә стадиясе булса да, миндә метастазалар киткән икән. Табиб 8 химия курсы һәм 25 нурланыш кирәген әйтте, – ди Алия. – Мин барысына да риза! Терелим генә! Менә беренче химияне алу көне дә җитте. Җиңел түгел. Әмма түзәргә кирәк! Чәчләр коела башлады. Химия арты химия. Чәчне кырдырырга кирәк икәнен аңладым. Миңа кыен икәнне кечкенә улым да сизде. Синең кебек булам дип, ул да чәчен алуны сорады. Ялгыз түгеллегемә тагын бер кат инандым. Гаиләм, туганнарым, дусларым, күршеләрем бар. Авыр чакта кемнең кем икәнен яхшы аңлыйсың икән.

Никадәр көчле булырга тырышса да, Алиянең химия терапиясе алган вакытларда төшенкелеккә бирелгән, мин башка булдыра алмыйм, дип әйткән чаклары да була. Әмма үз-үзен тиз кулга ала. Тормышның якасына ныклап ябыша. Яшисе килә бит! Дәваланып беткәндә инде ул бөтенләй башка кешегә әйләнә. Ашауны үзгәртә, бассейнга йөри башлый. Нурланыш терапиясе узганда эшкә чыга.

– Эштәге җитәкчемә дә рәхмәт. Ул да миңа яшәр көч бирде, – ди Алия. – Эшкә чыкканда башыма ни кияргә дип аптырап тормадым. Ул чакта яңа чәчләрнең үсеп кенә килгән чагы. Парик та кимәдем, башлык та. Ничек бар, шул килеш эшкә килдем. Шунысы кызык: 31 яшемә кадәр чәчләрем туры булса, дәвалганганнан соң миңа бөдрә чәчләр үсте. Химия ясаттыңмы әллә, диләр. Шаяртып, ясаттым, дим. Әмма башка төрлене, – ди Алия. – Синдә – яман авыру, дип әйтү җиңел ул, кабул итү кыен. Шуларны уйладым да, андыйлар өчен берәр проект уйлап табасым килде.

Шуңа да ул башкаларны да сөендерергә, аларга үзгәрергә ярдәм итәргә була. Эзләнә торгач, интернетта «мояфототерапия.рф» проектына тап була. Проект хуҗалары белән киңәшеп, Татарстанда да мондый эш башлыйсы килү теләген әйтә. Риза булган авыруларны да таба. Хәйриячеләр ярдәме белән Казанда да фотосессия ясыйлар. Фотога төшүчеләр арасында 5–10 ел дәвамында чир белән көрәшүчеләр, шушы авыруны кабул итеп яшәүчеләр була. Аларның фотоларыннан күргәзмә туплап, башкаларга күрсәтәләр.

– Мин бөтенләй башка кеше хәзер. Тормышка карашым үзгәрде. Үзеңне, тормышны яратырга кирәк! Вак-төяк мәшәкатьләр өчен борчылмаска киңәш итәм. Мин үз гаиләмнең кадерле булганын аңладым, – ди Алия. – Барысы да үзеңнән тора. Сәламәтлеккә битараф булмаска, вакытында табибка күренергә кирәк. Яман чир дәваланмый, димәгез! Аны да җиңеп була. Минем кебек!

Сынаулар узар әле...

Балык Бистәсе районының Күгәрчен авылында гомер итүче 40 яшьлек Сиринә Галимовага ярдәм кирәк. Медицина тикшеренүе узганда күкрәгендә шеш барлыгын күреп алган табиблар аны тизрәк Казанга җибәрә. Андагылар да сөендерми.

– Әниемнең кан анализларында онкомаркерлар күтәрелгән иде. Бер дә зарланмагач, без моңа артык игътибар да итмәдек. Әмма әкренләп чир баш калкытты. Әниемнең күкрәге шеште. Тикшерә торгач, барысы да ачыкланды инде, – ди кызы Диләрә. – Табиблар әниемә чирнең 4 нче стадиясен куя. Җитмәсә, бавырына да метастазалар киткән. Әлегә табиблар аны химия терапиясе белән дәвалый. Табиблар белеп эшлидер инде. Әни дә, без дә аның сихәтләнәсенә ышанабыз.

Сиринә ире белән өч бала үстерә. Иң олылары Диләрәгә – 20, Даниярга – 17, Тимерланга 7 генә яшь әле.

– Без – бик тату гаилә. Туганнар белән дә бер-беребезне якын итеп яшибез. Әнинең авыруы безне тагын да якынайтты. Әнигә дә җиңел түгел, эти дә бик борчыла. Сиздермәскә тырышсалар да, күрәбез инде. Бар теләгебез – бу сынауны узып, элеккечә тормышка сөенеп яшәргә иде, – ди Диләрә. – Минем балалар табибына укып, кулыма диплом алуымны, Даниярның төзүче булуын күреп сөенәселәре бар бит әле. Аңарчы Тимерлан да буй җитәр! Өч баланың туйларында да йөриселәре бар. Безгә әни бик кирәк.

Диләрә тиздән әнисе белән Мәскәүгә барырга җыена. Андагы табибка да күренеп карарга исәпләре. Инде язылып та куйганнар.

– Мин әметемне өзмим. Яшәсен иде әни! Ул үзе дә, чирне җиңәчәкмен, дип яши. Әнә шуңа да әнине дәваларга акча җыярга булдык. Безгә ярдәм иткән бар кешегә чиксез рәхмәт, – ди Диләрә.

Сиринә Галимовага булышырга теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:
Кызы Диләрә Галимова исемендәге **4276 6200 3751 6683** номерлы Саклык (Сбер) банкы картасы **89093147931** телефон номерына беркетелгән.

Бер күрүдән сиздем

Кызык бу дөнья! Кияүгә чыкканда күзгә ак-кара күренми икән. Менә гаилә корам да, барысын да көнләштереп, матур итеп яшим, башкалар ясаган ялгышны кабатламыйм, имеш! Мин дә шулай хыялландым.

Мин – авыл кызы, ә Рәнис – Казан егете. Өч ай очрашкач, ул мине әти-әнисе белән таныштырды. Шул көнне үк булачак каенанамның безгә мәңге тынычлык бирмәячәген аңласам да, аның улын ярату хисе өстенрәк чыкты. Рәнис минеке генә булырга тиеш дип яши башладым. Аны берәүгә дә бирәсем килмәде. Шул ярату харап итте дә инде мине. Танышып, ярты ел узды дигәндә, бергә яши башладык. Ике як әти-әнигә дә берни сиздермәдек. Әгәр никахсыз бергә торганны белсәләр, кирәкне бирәләр иде. Ике айдан авырга узганымны белдем. Белгәч, әниләр никах укыттылар.

Менә шуннан соң башланды инде хәлләр. Ирем дә үзгәрде, әнисе дә. Әти-әниемә берни кайтып сөйли алмыйм. Оят кирәк! Шулкадәр тырышлык биреп үстерде бит алар мине! Ә мин йөзләренә кызыллык китердем. Җитмәсә, каенанам сүз саен шуны төрттереп тора. Янәсе, бәбигә узмаган булсам, малаена алдырасы булмаган. Әле аңа 52 кенә яшь. Җанымны ашый инде. Бергә тормасак та, эштән кайтышлый көн саен безгә керә. Бөтен нәрсәне күзәтеп, тикшереп тора. Ни пешергәнмен, нәрсә эшләгәнмен, дөресрәге, ни эшләмәгәнмен һәм нәрсәне дөрес пешермәгәнмен? Сабыйның эче авыртса да, мин гаепле. Янәсе, теләсә нинди ризык ашап утырам. Атна ахырында авылга кайта башласак та, бездән калмый. Әйтерсең, минем әти белән әнинең атна саен кеше көйләп торасы килә.

Иремә дә әйтеп карадым, тик ул әнисен яклый. «Биш хатынга өйләнә алам, ә әни берәү генә», – ди. Менә сиңа мә! Кайчан үз тормышыбыз белән яшәрбез икән, дим. Кайбер танышларымның каенаналары, бераз ял итегез, бергә йөреп кайтыгыз дип, баласын алып кала. Ә минеке үзе ял итеп туймаган әле. Кайбер көнне театрдан соң да безгә кайтып куна.

Ирем бик бәхетле яши. Әни бездә кунган көннәрне улына иртәнге ризыкны да үзе пешереп ашата. Анысы тәмлерәк икән. Оныкка да исе китми, улы гына кирәк. Рәнисне гел үзе белән ияртеп йөртә. Кибеткә дә бергә баралар, базарга да. Аның белән икебез генә калган вакыт юк диярлек. Йә ул төнлә кайтып керә, йә инде әнисе бездә була. Үз әнием, сабыр ит, дип киңәш бирә. Ә мин арыдым инде. Ирем әнисенең итәгеннән кайчан төшәр дип көтә-көтә, еллар узып бара. Үземнең дә улым үсә! Инде бүгеннән үк үз-үземә сүз бирәм: аның гаиләсенә тыкшынмас идем. Башкаларның да каенаналары шундый микән ул? Өлкәннәр мине сабырсыз дип сүгәр, тик яшь чакта ярата, яратыласы да килә бит.

Ильмира ХАНОВА.
Казан

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

КЫЗЛАР, СЕЗГӘ ӘЙТӘМ

- Кызлар! Бизәнеп төшкән фотоларыгызны социаль челтәрләргә куюны туктатыгыз! Дәүләт сезнең аркада пенсия яшен арттыра.
- Бер серне чишәм сезгә. Шкафта озак киелми яткан кием кечерәя.
- Дәү әниегез сезгә «тазарып, матуреп киткәнсең» дисә, шатланырга ашыкмагыз.
- Бер акыллы кеше әйтмешли, кем икәнен хәтерләмим, нәрсә әйткәне дә истә түгел, әмма фикере бик кызык иде.
- Тазалык ул песигә генә килешә һәм бүләкләр капчыгына.
- Егетегез сезнең мәче белән артык дуслашмасын. Араларыгыз суынгач, аңа мәче белән аерылышу бик авыр булачак.
- Кызлар, сорауны дөрес итеп бирер өчен җавапның 70 проценты инде билгеле булырга тиеш.
- Әгәр сез бу дөньяга тугансыз икән, димәк, бу инде гомергә.

Әз-мәз мәзәк

– Син хәтта тапкырлау таблицасын да белмисең, улым!
– Хәзер, әти.
– Ник чыгардың телефоныңны? Калькулятор кабызмакчы буласыңмы?
– Алиса, ә нәрсә ул «тапкырлау таблицасы»?

* * *

– Тәмләп йоклар өчен пижама сатып алдым.
– Тәмләме соң йокың?
– Йокы пижамасына ни өчен кесә ясаганнар икән дип уйлап, төне буе йоклый алмадым.

* * *

Пычагымамы бу миңа дип уйлап куям кайвакыт. Ә «пычагыма» җавап бирә: «Шулай кирәк!»

* * *

– Ало! Әни! Мин ишекне шапылдатып яптым да, ачкычым фатир эчендә калды. Инде нишләргә?
– Кем сез? Мошенникмы? Мин мондый шалтыратуларга ышанмыйм!



Сканворд җаваплары

Горизонталь: җәмәгать, шалкан, Ли, арпа, Еники, Кант, Сы, буй, Әзһәмова, Рая, Искәндәр, әрекмән, икс, әр, Алиса, тәбәр, кайнар, бара, икенде, пан, бәла, асу, РТР, ызан, аркылы, әби, Рәкыйп, иш, Сникерс, Ләбиб, олуг, ак, веранда, әл, Кушлавыч, Ямаширмә.

Вертикаль: Җәмилә, Сбербанк, зирәк, ераклык, азык, Мимино, ай, Алекно, Анпилов, Тина, Винарис, Шәле, инша, куа, бурыч, акт, ипи, Рәбига, фри, бәс, сәнәк, су, КИА, адәм, шагыйрә, Берлин, кала, Анита, Ты, Ядкәр, як, әсбап, Арбор, Нәбирә, яран, Сәнифә.

Беләсең килсә...

1 Иң кайнар планета нинди?

а) Марс;
б) Венера;
в) Сатурн.

2 «Мона Лиза» рәсемен кем ясаган?

а) Леонардо да Винчи;
б) Пабло Пикассо;
в) Винсент Ван Гог.

3 Язучы Гәрәй Рәхимнең паспорт буенча исеме ничек?

а) Георгий Рахимов;
б) Григорий Родионов;
в) Георгий Родионов.

4 Осьминогның ничә йөрәге бар?

а) 1;
б) 2;
в) 3.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Газетаның киләсе саны 28 февральдә чыга.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 227

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+